ИВАН КИНДЕР
АЛТЫНКАЙ



ИВАН КИНДЕР

АЛТЫНКАЙ

Хикәяләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1993

ББК 84Р7-4
К 38

Художнигы И. ВОРОБЬЕВ

Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларына

К $\frac{4803010201-065}{М132(03)-93}$ 108—93

ББК 84Р7-4

ISBN 5—298—00389—3

© Татарстан китап нәшрияты, 1993

КОМДАГЫ ЭЗЛӘР

Бу хәбәр тиз арада бөтен урамга таралып, халыкның ачуын чыгарды.

— Куллары кычыткандыр кансызларның!

— Тотып ярасы иде хәсисләрне! — дип, әлеге вакыйгага карата карты-яше үз фикерен әйтте.

Ә вакыйга дигәнебез менә болай булды.

Кемдер берәү камышлы күл култыгында шактый гына баканы кырып, үтереп киткән иде.

Кайбер хулиган малайлар элек-электән бака күрсәләр, тиктомалга таяк күтәрәләр яки таш орып, аяк белән сытып китәләр. Юк, бу бәндә алай гына эшләп калмаган. Моны ниндидер салкын кан белән, алдан уйлап эшләнгән явызлык, хәтта ерткычлык дип атарга мөмкин иде. Үлеп яткан бакаларның һәрберсенең авызында папирос төпчеге. Димәк, алар агулы төтен йотып, сулышлары буылып үлгәннәр...

Яр буенда андый «тәмәкече» бакаларның исәбе-саны юк иде.

Комлыкка килеп туктагач, Костя минем кулымнан кысып тотты:

— Күр әле, өреп кабарткан кебек.

Минем аяк янында гына җилем туп кебек кабарган җансыз зур бер бака гәүдәсе ята иде. Карт бака булгандыр, күрәсең. Яшькелт-соры төстә. Яшь бакалар, гадәттә, суүсемнәр кебек ачык яшел төстә була. Төнбоек яфрагына менеп утырса, аера да алмассың. Ә бу бичара... Тиресен барабанга тарттырганнар диярсең. Эссе кояш нурында ярылып-ярылып кипкән. Әз генә кагылдыңмы, бөтенләй шартлап ярылыр кебек тоела. Ә кояш кыздыра да кыздыра.

— Мескен бакалар! — дидем мин.— Кызу булганга шулай күбенгәннәрдер инде болар.

Костя иңнәрен генә җыерып куя.

— Әллә кызудан, әллә тәмәке төтененнән,— ди ул әкрен генә.— Билсәпит насосы белән өреп кабарткан кебек...

Ул ипләп кенә аяк бармаклары белән баканы этәрә.

— Кагылма, юләр,— дим мин аңа.— Әнә бит, хәзер шартларга тора.

— Берни дә булмас...

Костя, иелеп, җирдән бер камыш сабагы ала, шуның белән баканың авызын ачтырып, папирос төпчеген тартып чыгара да әйләндерә-әйләндерә карый башлый. Төпчек ике урыннан бармак белән яньчелгән, юка кәгазенә «Казбек» дип язылган. Папиросның тәмәкеле өлеше шактый кыскарган. Күрәсең, теге явыз бәндә папиросны башта үзе тарткан, аннары, көйрәп торган килеш, бака авызына каптырган.

Бакалар һаваны, авызларын япкан килеш, борын куышлыгы аша сулыйлар да эчкә йотып җибәрәләр. Ә монда һава урынына әче төтен!.. Төпчекне төкереп ташлар әмәл дә юк, тамак төбенә үк этеп керткәннәр.

Кем шулай азаплагандыр җан иясен?! Безнең урам малайлары арасында тәмәке тартучы юк. Табышмак дисәң дә табышмак!

— Кая илтик инде боларны? — дим мин, аптырап.— Суга ыргытыйк, хет җәеннәр ашасын.

— Тәмәкә исе аңкып торгач, нинди җәен кагылсын! — ди Костя.— Суны пычратып, өстә йөзеп йөрерләр. Әйдә, җиргә күмик.

Мин ярның текә төшкән урынына барып, казыкка бәйләп

куелган көймәбездән ишкәк алып килдем дә җир казырга керештем...

Өйгә без шактый төшенке кәеф белән кайттык. Бака дисәң дә җан иясе бит. Әнә, узган ел да шундыйрак бер хәл булган иде: кемдер берәү текә ярдагы керәшә ояларын төрле чүп-чар белән дөңгечләп томалап киткән. Ярый әле вакытында күреп калдык. Ә менә бу явыз бәндәләрне һичберебез күрмәгән. Әгәр күргән булсак...

Костяны да һаман шул бер уй борчып килә икән.

— Ә син беләсеңме? — диде ул кинәт кенә. — Япониядә бакаларга һәйкәл куйганнар. Ни өчен дисеңме? Кешеләргә, фәнгә күп файда китергән өчен. Безнең илдә дә шундый һәйкәл бар. Ленинградта. Тик анысы бакаларга түгел, этләргә куелган һәйкәл.

— Шыттырмыйсыңмы? — дим мин.

— Шыттырырга, мин бака газраиле түгел, белдеңме?!

Минем сүзләргә Костяның хәтере калган иде, күрәсең. Ул беразга тынып калды, аннары янәдән телгә килде:

— Әгәр бик беләсең килсә, бакалар инде космоска да менеп төштеләр.

Бу турыда минем кайчандыр укыганымны, ишеткәнемне бар иде. Тик кайчан икәнен анык хәтерли алмадым. Шуңа күрә дәшми калу хәерлерәк булыр, дип уйладым. Без тын гына атлый бирдек.

Кинәт кенә талгын җил исеп куйды, күл шадраланды, озакламый йөгерек дулкыннар да уйный башлады. Дулкыннар бер-бер артлы күлнең сөзәк ярына шуыштылар, юеш ком өстендә ак күбек тасмасы сузылып калды. Без, яланаякларыбызны салкынча суда юдырта-юдырта, күл читеннән атладык. Әмма бүген бу хозурлыктан күңелдә гадәттәге рәхәт омтылыш хисе уянмый иде. Һаман шул тончыгып үлгән бакалар истән чыкмый.

Дөрес, бу җан ияләренә карата төрле кеше төрле фикердә. Берәүләр баканың файдалы якларын күреп соклана. Соң инде! Уйлап кара, бер бака җәй буена күпме чебен-черкине, күпме канэчкеч озынборынны юк итә. Артык каударланып, бөҗәк артыннан куып та йөрми. Җай килгәнен көтеп кенә утыра да, уттай җитез озын теле белән ялмап кына ала. Күз дә иярми кала.

Ә чисталык, пөхтәлек дигәндә бакадан уздырган тагын нин-

ди җан иясен табарсың! Көннең-көн буе суда йөзеп-чумып мәш килә. Яр буена чыгып яки берәр ауган агач ботагына, төнбоек яфрагына менеп бераз вакыт кояшта кызына да янәдән чултыйх! Шуңа да карамастан, кайбер бәндәләр бакага җирәнеп карый, борын җыера. Янәсе, әнә нинди кыяфәтсез, килбәтсез мәхлук. Җитмәсә, әллә нинди тузга язмаган имеш-мимешләр дә сөйләп йөриләр. Имештер, бака тоткан кешенең кулы чабыра, бетчә баса, сөял чыга. Андый тозсыз әкиятне кем уйлап чыгаргандыр, әмма аңа ышанучылар әле хәзер дә җитәрлек. Әлеге чиркандыргыч тамаша да шул коткы нәтиҗәседер, мөгаен.

— Шулай да ни сәбәпле барысы да кырылып бетте икән бакалар? — дип төпченәм мин.— Юкса бит алар әнә ничек яшәүгә хирыслар!

— Күреп торасың бит,— ди Костя.— Тәмәке төтене алар өчен иң зәһәр агу. Бер йоттымы — вәссәлам!

— Кире өреп чыгарсалар ни булган?..

Костя һәрнәрсәнең төбенә төшкәнче тикшеренергә, очына чыкканчы төпченергә ярата. Шуңа күрә ул өзә-каба җавап бирми, башта озак кына уйланып бара.

— Ә өреп чыгара алмаса? — дип, сорауга каршы сорау куя ул.— Агулы төтен кире чыкмаса, нишләргә?

— Нигә чыкмасын икән?

— Нигә-нигә! Үз башың белән уйлап кара. Эчкә сулаганда һава белән бергә төтен иркен керә, ә чыгарырга җай юк. Чөнки тамак асты мускуллары эшләми, чөнки авыз буш түгел.

— Соң, алайса, су астында ничек сулый?

— Анда тән тиресе белән.

Костя тагын озак кына сүзсез атлый. Аннары, үз уйларына җавап биргәндәй итеп, әкрен генә әйтеп куя:

— Сөкә белән тотканнар, күрәсең. Кул белән тота алмаслар иде ул тикле җан иясен. Балык каптырырга килгән кешеләр инде. Авызына тәмәке кабып, сикерешеп йөргән бакалар кызык тоелгандыр кансызларга.— Күл ярының дугаланып борылган җирендә Костя кинәт туктап кала, иелеп, ком өстендә аунап яткан папирос төпчеген ала да әйләндергәләп карый башлый.

— Син Шерлок Холмс кебек,— дим мин аңа.— Зурайткыч пыяláң да булса...

— Лыгырдап торганчы үзеңә берәр эш тап! — ди Костя.
— Нинди эш?
Иптәшем тагын тынып кала.
— Әйт әле, ник килдек без бирегә? — ди ул аннары.
— Нигә булсын? Уйнарга, ял итәргә.
— Аның өчен бирегә килеп йөрмәскә дә була,— ди ул, кырыс гына итеп.— Гаепле кешеләрне эзләргә кирәк. Аңладыңмы? Табигатьне сакларга. Менә, кара!

Ул кулындагы папирос төпчеген миңа сузды. Төпчеккә шактый эре хәрефләр белән «Казбек» дип язылган иде.

Костя папиросның бармак белән кысып яньчелгән урынына төртеп күрсәтте.

— Ә менә монысына ни әйтерсең?

Ныклабрак карасам, исем китте. Ничек моңа кадәр игътибар итмәгәнмен? Бу төпчек тә нәкъ теге бака авызындагы папирос кебек яньчелгән икән ләбаса! Бер-берсеннән һич аера алмассың. Чын эзтабар икән бу Костя! Баштан ук бөтенесен хәтеренә сала барган.

— Төшенә башладыңмы инде хәзер? Минемчә, бу бәндәләр станция ягыннан килгән,— дип куйды Костя, ерактан күренгән тимер юл вокзалы ягына карап.— Яланаяк йөргән үзләре. Ә станция сукмагында гел чуерташ. Йөреп кара шунда аягыңа кимичә!

Без станция малайларын берәм-берәм барлап чыктык. Карасаң, берсе дә андый ук юньсез түгел икән бит. Дөрес, башта Сеня исемле малайга шигебез төшкән иде. Ул яз көне үзләренең ялкау мәчесенә күлдән чукмарбашлар тотып ашата иде. Шуңа күрә аңа «бака аучысы» дигән кушамат та такканнар. Ләкин тәмәке тартмый. Аннары, ни сәбәпле тиктомалга бака үтереп йөрсен, ди ул? Әле киресенчә, бакалар бетсә, аның мыраубикәсенә чукмарбашлар да эләкмәячәк. Димәк, ныклап уйлаганда, Сенядан шикләнер урын юк.

— Читтән кунакка килгән берәр сукбай түгелдер бит? — дип куйды Костя.— Алай дисәң, бу арада ят малайлар күренгәне юк кебек.

Иптәшемнең бу сүзләрен ишеткәч, мин, үзем дә сизмәстән, кычкырып ук җибәрдем:

— Тукта-тукта, торып тор! Нишләп әле гел малайларга гына сылтарга? Олы кешеләр арасында мәгънәсез сукбайлар юкмы әллә?

Костя миңа карап көлеп куйды:

— Әллә син дә эзтабар булып китәсең инде? Доктор Ватсон кебек. Әйдә, эшләт әле баш миеңне. Икәүләп керешкәч, ничек тә очына чыкмый калмабыз.— Ул берәм-берәм бармакларын бөгеп санарга керешге.— Беренчедән, бу бәндәләр каян килгән? Икенчедән — ничә кеше? Өченчедән — кемнәр? Шылдымы?

— Шылды.

Без, үзебез дә искәрмәстән, вокзал сукмагына борылдык. Тик хәзер инде без җил куып йөрүче гамьсез малайлар түгел. Без — эзтабарлар. Җинаятьчеләр калдырган эзләрне юллыйбыз. Нинди эзгә төшәсебезне әлегә үзебез дә анык белмибез. Ләкин безнең күз карашлары сукмакның һәр адымын, һәр карышын җентекләп капшап бара. Анда аунап яткан һәр төпчек, һәр кәгазь кисәге, хәтта һәр таш безнең игътибарны җәлеп итә.

Күл буенда халык күп йөргән. Комлы сөзәк ярларны таптап бетергәннәр. Юеш комдагы ачык уелып калган эзләрне йөгерек дулкыннар юган, ак күбек каплаган. Ә биредә — ташлы сукмак. Рәтләп күзгә ташланырлык эз дә юк. Биредә дәлил итеп алырлык бер әйбер кисәге дә күренми. Сирәк-мирәк узып киткән кешеләрнең беленер-беленмәс эзләрен шунда ук җилбәзәк җил ялмап ала.

Менә сукмак тар гына инеш үзәненә, иңкүрәк урынга сузылып төште. Ком өстендә сукмактан бераз читтәрәк аермачык булып эзләр ярылып ята. Чыршы ботагы кебек кыйгач сырлы эзләр. Резин башмак эзләре!

— Тукта-тукта! — дип пышылдады Костя ничектер серле итеп.— Ныклабрак карыйк әле. Синеңчә, нинди аяк киеме булыр бу?

— Кеда эзенә охшаган.

Бу тирәдә итек, башмак, ботинка эзләре дә бар иде. Ләкин Костя аларга игътибар итмәде.

— Син хаклы,— диде ул, берничә эзне тикшереп чыкканнан соң.— Балыкка йөрергә, сәяхәткә чыгарга иң уңай аяк киеме — кеда. Шушы эзләрне күздән югалтмаска кирәк.

Кеда эзләре шактый зур иде. Моның хуҗасына кимендә унбиш-уналты яшьләр булырга тиеш. Димәк, бездән ике-өч яшькә өлкән.

— Табан эзендәге сырларны хәтереңдә калдырырга тырыш,— дип пышылдады дустым.— Рәсемен алсак, бигрәк шәп булыр иде дә, үч иткәндәй, бүген кәгазь-каләм алмаганмын.

Мин артык сораштырып тормыйм. Шерлок Холмсны укыганым бар, калганын киләчәк күрсәтер. Ә табандагы сыр-сурәтләр артык катлаулы түгел: дулкын-дулкын аркылы сызыклар, ә үкчәдә — вак кына шакмак.

Бу эз янәшәсеннән тупак башлы сандалет атлап бара. Аныңсының табанында сыр-фәлән юк. Ә зурлыгына караганда, кеда хуҗасы белән бер яшьләрдә булса кирәк. Табанның арткы өлешенә тимер дага кагылган. Туфракның дымлырак урынында хәтта кадак эзләре дә төшеп калган.

Бу табышыбыз безне канатландырып җибәрде. Ни әйтсәң дә, хәзер безнең кулда җинаять йомгагын сүтә башлау өчен дәлилләр бар. Дөрес, әле аларны артык ышанычлы дәлил дип әйтеп булмый. Нибарысы шул ике эз дә бердәнбер төпчек. Эзләр кемнеке икәне дә билгеле түгел: әллә алар, әллә бөтенләй башка кеше. Тик төпчек кенә, һичшиксез, җинаять шаһиты. Костя аны зур саклык белән, калай банкага салып, кесәсенә тыкты. Банкасын да алдан әзерләп килгән диярсең!

— Ә бәлки, алар машина белән килгәндер,— дим мин.

— Юк! — дип кырт кисә Костя.— Кая, алайса, машина эзләре?

Тиздән без тагын бер төпчек табып алдык. Ләкин анысы безне чак кына эздән яздырмый калды. Зурлыгына караганда, ул тегесе белән бер чама иде. Тик бармак белән яньчелгән эзләр юк. Үзе күптән түгел генә тартып ташланганга охшый. Саргаймаган, пычранырга да өлгермәгән.

Без аптырашка калдык.

— Йә, инде ни әйтерсең, Шерлок Холмс? — дим мин.— Төп башына утырдың түгелме?

Костя ләм-мим сүз дәшми, кашын җыерып, тирән уйга баткан. Үзе һаман төпчекне әйләндергәли...

— Менә кара! — дип кычкырып җибәрде ул кинәт кенә.— Кара, күр! «Любительские» дип язылган. Бутыйсың гына син, хәсрәт Ватсон! Бөтен эшне чуалта яздың.

— Ә нишләп?

— Нишләп, нишләп!.. Бу төпчек бөтенләй башка кешенеке. Җинаятьченең эзенә төшү өчен безгә бары тик «Казбек» төпчеге генә ярый.

Баксаң, дөрестән дә... Мондый чебердекле эштә буталып калуың бик тиз икән шул. Ә инде җепнең очын чуалтсаң, табып кара аны яңадан! Әнә бит, бер карасаң, нәкъ шундый ук төпчек.

Ярый әле, эзтабарлык эшендә Костя шактый күпне белә. Мажаралы китапларны өзми-куймый укып ятуы юкка гына булмаган икән.

Станциягә барып җитәрәк без тагын бер «Казбек» төпчеге таптык. Костяның йөзе шунда ук яктырып китте:

— Менә! Менә! Күрдеңме инде? Әйттем бит!

— Күрдем. Тик нишләп һаман берәү генә?

— Дөрес. Тегендә, күл буенда да берәү генә иде. Димәк, икенчесе тартмый. Монысын да теркәп куясы булыр.

Үзенең бу ачышыннан канатланып, Костя төпчекләрне каткат чагыштырды. Күзләрендә тәвәккәл чаткылар кабынды.

— Димәк, безнең кулда хәзер өч факт бар! — диде ул, тантаналы итеп.— Нindиләр, дисеңме? Җинаятьчеләр икәү булган. Берсе «Казбек» папиросы тарта, икенчесе тартмый. Берсе аягына сырлы табанлы кеда кигән, икенчесе — тупак башлы сандалет...

Перронда һичбер җан иясе юк иде. Расписание буенча соңгы поезд моннан ике сәгать элек кузгалган. Ә икенчесе — сәгать сигезенче яртыда.

— Инде нишлибез?

Расписаниегә тагын бер кат күз төшереп алганнан соң, Костя озак кына уйланып торды.

— Мин менә болайрак фикер йөртәм,— диде ул, кул аркасы белән маңгай тирен сөртеп,— узгынчы поезд белән бирегә иртәнге җидедә килеп төшәргә була, ә кире китәргә — әбәт алдыннан. Бусы — бер. Иртәнге икенче поезд алай уңайлы түгел — анда килә. Үзен уйлап кара, көн кызуында нинди балык чиртсен! Коенырга, кызынырга була, әмма...— Костя, тамагына бәрәңге тыгылгандай, кинәт йотлыгып калды.— Тукта-тукта! — дип кычкырып җибәрде ул аннары.— Әгәр алар су коенырга, комда кызынырга гына килгән кешеләр булса... Балык тотканда кем инде бака куып йөрсен?! Аңлашылды бу, арка кыздырырга килгән эшлексезләр болар. Шуңа күрә иртән без балык тотканда күзгә чалынмыйлар. Якын-тирәдә безнеке кебек матур, чиста күл юк. Җитмәсә, нинди әйбәт комлык. Поездлар вакытында йөреп тора...

— Көн саен кем инде поезд белән кызынырга йөрсен? — дип, шигемне белдердем мин.

Күрәм, Костя да шөбһәгә калды...

— Тикшерергә кирәк,— диде ул, шактый вакыт уйланып тор-

ганнан соң.— Төбенә төшкәнче тикшерергә! Иртәгә таң белән кузгалабыз, аңладыңмы?

Иртән вокзалга Костя миннән алданрак килеп җиткән иде. Шакмаклы күлмәгенең түш кесәсеннән шарикლы ручка башы төртеп тора. Иңенә бинокль аскан.

Бүгенге иртә шактый салкынча. Вокзал бинасы, тирә-яктагы зифа тупыллар — барысы да бил тиңентен иртәнге томанга күмелеп утыра. Тимер юл рельсларын, перрон асфальтын куе чык сарган. Шунлыктан алар кара-кучкыл булып күренәләр. Тып-тын, яфрак лепердәтерлек тә җил әсәре юк.

Иртәнге поездтан безнең станциядә һичберәү төшмәде. Димәк, кайтып бераз йоклап алырга да була.

— Онытма, икенче поездга ун тулганчы килеп җит,— диде Костя.

Без йокы туйдырып чыкканда көн чалт аяз иде. Вокзал тирәсенә дә җан кергән, перрон артындагы базар кайнап тора. Анда сөт-катык, пешкән бәрәңге, тозлы кыяр саталар. Халыкның төрлесе үтеп-сүтеп йөри, төрлесендә төрле аяк киеме. Берәүләр поездга ашыга, берәүләр төшә. Без, бер читкәрәк басып, һәркемне җентекләп күздән кичерәбез. Тик эзләгән кешеләребез күренми.

— Иртән салкынча булды, хәзер җил исеп тора,— диде Костя.— Коенырга кулай көн түгел. Менә шуңа юк алар. Күл буена биредән шул бер генә сукмак. Күрми калмас идек.

Әмма көн үзәгендә су коенырга баргач, исебез-акылыбыз китте. Күлнең комлы ярында тагын җиде-сигез бака үлеп ята иде. Һәммәсенең авызында шул ук «Казбек» төпчеге, барысы да туп кебек күбенгән. Җан ияләренең газапланып үлүеннән нинди ерткыч бәндәләр ләззәт таба икән!

Тирә-як тып-тын калган, хәтта камышлар да шауламый. Әйтерсең алар да бу вәхшәтне күреп башларын игән иде.

— Ычкындырганбыз! — диде Костя, еларга җитеп.— Шунда, станциядә кәтәсе булган.

— Кем уйлаган бит!..

— Әйе шул. Алдан белеп булмый.

— Әйдә, карыйк әле, эзләре юкмы?

Ләкин, күпме генә карасак та, яр буенда әлеге сырлы кеда һәм дагалы сандали эзләре күренмәде. Комның юеш урынында тик яланаяк эзләре генә аермачык ярылып ята иде.

— Бүген яланаяк килгән, ахры, болар,— дим мин.

— Юк,— дип кырт кисә Костя,— яланаяк йөрергә малай-шалай түгел инде алар. Житкән егетләр дияргә була. Ул яшьләрдә урам буйлап яланаяк йөрмиләр.

— Бу бит урам түгел.

Минем бу сүзләрне ишетүгә, Костя кинәт шым калды. Аннары, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кызу-кызу атлап күл башына таба китеп барды. Шул тикле ашыга, хәтта мин артыннан житә алмыйм. Кабалана торгач, сулышым капты.

Костя ашыгып барган жиреннән кырт туктады да жиргә иелде:

— Кил тизрәк, нәрсә сөйрәләсең? Әнә, күр!

Карасам, нәкъ шул кечәге эзләр. Костя хәтереннән сурәтен дә сызгалап алган икән. Чагыштырып карагач, һичбер шигебез калмады.

— Комда яланаяк йөргәннәр,— ди Костя.— Сукмакка килеп житкәч кенә кигәннәр аяк киемнәрен. Менә сандали эзе дә.

— Ә сөкә? — дим мин, иптәшемнең кичәге сүзләрен хәтерләп.— Балык тотасы булмагач, сөкә нигә кирәк аларга?

— Аптыратма юкка,— ди Костя.— Бар аларның сөкәсе. Әйткән иде диярсең менә! Хәзер безнең тотыныр нәрсә житәрлек. Ачыклыйсылары да шактый. Әйтик, поезд... Кайсы сәгатьтә, кайсы юнәлештән? Кайсы станциядән килүләре ихтимал? Аннары инде жинаять өстендә килеп тотсак...

— Ә тотсак нишләтербез?

Минем бу сорау Костяны да аптырашка калдырды.

Чыннан да, тотып нишли алырбыз?.. Бу юньсезләрне акыл сатып кына жүнгә китерә алмассың. Эш якалашуга барып житәчәк.

— Әгәр язу язып элсәк? — дим мин.— Әйтик, мондыйрак язу: «Бакаларны үтерү тыела!»

— Тукта, тукта! Дөрес сукалыйсың түгелме әле син, Ватсон! — ди иптәшем.— Алай да булмаса, рыбнадзорга хәбәр итәрбез. Акимычка.

— Акимыч? Нишләп инде Акимыч бакалар артыннан йөрсен!

— Ә ник йөрмәсен! Бака-бака, имеш! Уйлап кара, бака ул — табигатьнең бер кисәге. Галимнәр хәзер кайбер бөжәкләрне дә «Кызыл китап»ка бастырып саклыйлар, беләсең килсә. Табигатьтә һәрнәрсә бер-беренә бәйле. Нәкъ чылбыр кебек. Бер бөжрасын өзсәң, күп нәрсә харап була.

Без шунда ук өйгә әйләнеп кайттык та эшкә керештек. Костя зур гына фанер кисәгенә кара буяу белән язу язарга тотынды, мин казык юндым, әйбәтләп шомарттым, очын очладым. Шул ук көнне, күл буена илтеп, кагып та куйдык. Карасак, менә дигән чыкты!

Кичкә таба камышка яшергән кармакларыбызны алып, бөдрә тал-тирәк төбенә балык тотарга утырдык. Ике көн кармак салганыбыз юк иде инде. Күңелләр бераз тынычланып китте.

Бездән ерак та түгел бер бака малае төнбоек яфрагына менеп утырган да нәрсәдер күзәтә, хәтта кизәнеп кармак ыргытканда да кымшанмый. Хәрәкәтләнми. Дус белән дошманны ул да аера, ахры! Күл өстендә тагын берничә бака ялкау гына йөзеп йөри, борын очлары белән ике күзе генә судан чыгып калган. Менә арадан берсе әкрен генә:

— Уик-уик,— дип кычкырып куя.

— Иптәшләрен чакыра! — ди Костя.

— Әйтерсең инде син!

— Күрерсең менә, берәр сәгатьтән чын концерт башланыр. Аларның әле куркыныч янаган чакта кычкыра торган сигнал авазлары да бар. Тре-ке-ке!..

Костя нәкъ бака кебек бакылдарга кереште. Шунда ук төнбоек өстендә утырган бака малае юкка чыкты, йөзеп йөргәннәре дә төпкә чумды.

— Күрдеңме инде! — дип көлә Костя.

— Чыннан да! — дим мин, гаҗәпкә калып.— Ничек шуны моңарчы искәрмәгәнмен?

Эңгер-меңгер вакытта балык бер-бер артлы каба башлады. Ләкин бүген кич клубта кино буласы иде. Аңарчы кайтып балык чистартасы да бар.

Иптәшем куканга тезгән балыкларын судан тартып чыгара.

— Җитешле булган бу бүген,— ди ул.— Безнең әни майда кыздырган алабуганы үлеп ярата. Кайтыйк әйдә караңгы төшкәнче.

Акимычларның капка төбендә коляскалы мотоцикл тора. Кертеп куймаган, димәк, каядыр китәргә җыена.

— Куна китмәгәе,— ди Костя.— Район зур, бер китсә, тиз генә кайтмас. Браконьерлар кайда да җитешле. Әйдә, барыйк әле.

Шул арада капкаларыннан Акимыч үзе дә килеп чыкты. Йөзе чуен кебек булып җилдә, кояшта каралган. Күркәтәй ак сакалы юри ябыштырып куйгандай аерылып тора.

— Әһә, менә кайда икән ул браконьерлар,— диде Акимыч, йөзенә кырыс кыяфәт бирергә тырышып.— Кая әле, кая, законга сыямы икән сезнең табыш?

Ул безнең куканнарны алып, кулында селкеткәләп карады:

— Ие, икешәр кило чамасы булыр, ягъни мәсәлән, закон киртәсен узмаган. Хуп, мәслихәт! Ничек соң, тартырга юкмы сезнең?

— Тартмыйбыз,— дидек без, икебез беравыздан.

— Дөрес эшлисез! — дип хуплады Акимыч.— Юкса, кайбер хәсрәт балыкчылар, күл буенда саф һава сулыйсы урынга, көн буена тәмәке пыскыта. Җитмәсә, төпчеген бака авызына тыгып китә, имгәк!

Без кинәт телсез калдык. Димәк, Акимыч та белә, бакалар өчен ул да борчыла икән.

Мотоцикл бишегеннән — ул шлемын алып киде, күн перчаткаларын тезенә бәргәләп какты.

— Бер генә тапкыр да түгел,— дип дәвам итте ул.— Кулы кычыткандыр азгынның! Берсен искәрдем искәрүен. Шәһәрдән әбиләренә кунакка кайткан. Шавалиха карчыкларга. Әбисе әйбәт кеше, сугыш вакытында хәтта председатель булып та торды. Оныгы кемгә охшап шулай юньсез булгандыр. Бала-чаганы җәберли, күркәдәй кукраеп, «Казбек» папиросы пыскытып йөри. Балыкка да егермешәр кармак тезеп төпкә сала. Тыелган ау дип тормый. Авылда үзенә бер иш тә табып алган инде. Сезгә менә нәрсә әйтмәкче идем, дуслар: мин ике-өч көнгә эш белән китеп барам. Мин юкта караштырыгыз әле сез күлне. Тотылмаган карак — карак түгел, ди. Җинаять вакытында кулларыннан тотып аласы иде каһәрләрне. Алай-болай булса, ярдәмгә өлкәннәрне дәшегез. Йә, ничек, булдыра аласызмы?

Без бүген Акимычка барысын да ачып салырга уйламаган идек. Карасаң, ул үзе дә искәреп йөри икән ләбаса. Болай булгач, яшереп торуның кирәге дә юк!

— Эзләренә басып киләбез инде,— дип кычкырдык без.

— Йә, йә, шуннан?

Без, бер-беребезне бүлә-бүлә, бөтенесен сөйләп бирдек. Төпчекләр турында да, язып каккан тактабыз хакында да әйттек.

— Менә ничек! — дип кеткелдәп көлде Акимыч.— Бик шәп эшләгәнсез, егетләр. Тик ул бәндәләр колак салырмы икән сезнең кисәтүгә? Ай-һай!

Ул бераз вакыт уйланып торды.

— Ундагы поезд белән киләләр, дисезме? Алайса, миңа бу сәфәрне кичектереп тору хәерле булыр. Күрше авылда йомышларым бар, иртән әйләнеп кайтырмын. Ә унынчы яртыда әзер булып торыгыз, операцияне шунда башлап җибәрербез. Сөйләштекме? — Акимыч безгә көрәктәй зур кулын сузды.— Мәгез, бишне, егетләр. Болай булгач, эзләренә басмый калмабыз.

«Ява» мотоциклы зырылдап, ыргылып кузгалды.

Төннең-төн буена йокым йокы булмады. Өндәгесе төштә, дигәндәй, һаман шул явызлар белән саташып беттем... Таң беленүгә, тиз-тиз генә киенәм дә Костяларга йөгерәм.

Ул да рәтләп йоклый алмаган, күрәсең, капка төбендә үк очрады. Иңендә — бинокле.

— Пассажир поезды әле яңа китте,— диде дустым.— Шулай да барыйк әле күл буена. Ни буласын кем белгән.

Авыл башына чыгу белән, Костя биноклен күзенә китерде һәм ... шунда ук, корт чаккандай, сискәнеп китте.

— Кара! — диде ул, биноклен миңа сузып.— Кемнәр йөри анда иртә таңнан?! Безнең авыл малайлары түгел бит болар!

Әйе. Үзебезнең малайларны без, Костя әйтмешли, мичкә керсә, чалбар төбеннән таныйбыз. Юк, безнекеләр түгел болар.

— Тегеләр! Валлаһи, шулар! — дип пышылдады дустым.

Солдатлар кебек иелә-шуыша күл башына кадәр йөгереп бардык та текә яр астына яшерендек. Әлеге сырлы кеда эзләре күзебезгә ташланды. Өр-яңа, әле генә узган эзләр. Шик-шөбһәгә һичбер урын юк — җинаятьчеләр үз шөгылендә.

Табигать корткычлары, атап килгәндәй, без язып элгән такта янына урнашканнар. Менә алар кинәт икесе тиң аягүрә бастылар да белдерүебезне таягы-ние белән суырып алып, куе камыш арасына томырдылар.

— Башланды! — дип пышылдады Костя.

— Нәрсә? Нәрсә башланды?

— Әнә, кара үзең.

Бинокльдән карагач, миңа да аермачык күренде. Тегеләр яшергән урыннарыннан төпкә сала торган тезмә кармакларын

тартып чыгардылар, бер-бер артлы җепләрен сүтеп, ком өстенә сузып салдылар, суалчан тезделәр.

Шунда Костя миңа төртте:

— Болай эшлибев: мин хәзер Акимычны чакырырга китәм. Поезд әле тиз генә килми. Ә боларның җәяү ычкынуы да бар. Син ни... җибәрми тоткарлап тор үзләрен. Аңлашылдымы?

— Шылды. Бар, тизрәк йөр.

... Әнә браконьерлар, тезмә кармак җепләрен авызларына кабып, күлгә кереп киттеләр. Кармак салып чыккач, җылыну өчен яр буенда сикергәләргә керештеләр. Аннары тәмәке кабыздылар... Юк, тәмәкене тик берсе тартты, төпчеген кая куйды — абайламый калдым. Әллә күлгә атты, әллә... бака тотканнары да күренмәде. Үзләре кармакларына да һич игътибар итми кебек. Бераз гына вакыт тын утырдылар да, аннары бер-беренә ком сибешергә, көрмәкләшеп аунарга, көч сынашырга керештеләр.

Шактый вакыт узды. Менә егетләрнең берсе, торып, күл кырына юнәлде, чирканып кына суга керде, икенчесе аңа капчыкка охшаган бер нәрсә илтеп тоттырды. «Сөкә!» дигән уй килде минем башка.— Нәрсәгә кирәк икән ул аларга хәзер? Бака тотыйм дисәң, аның өчен суга керәсе дә юк... Күп тә үтмәде, комлык читендәге камышларны аралап, ул иптәше янына килеп чыкты. Кулында сөкә, ә анда эре-эре бәртәсләр, алабугалар, кызылканатлар сикерешә, хәтта бер-ике сазан да бар кебек...

Менә алар балыкларын озын куканга тезделәр дә яңадан тез тиңентен суга керделәр, куканнарын камыш арасына яшереп, бау очын ниндидер төп башынамы, казыккамы бәйләп куйдылар. Үзләре, карак кебек, туктаусыз ялт-йолт каранадар. Хәер, браконьерның карактан ни аермасы бар! Карак кеше таласа, болар табигатьне талый. Ике чабата бер кием. Тик хәзер инде аларның барлык кыңгыр эшләре миңа мәгълүм.

Костя белән Акимыч килеп җиткәнче китеп кенә бармасыннар! Юкса, аларны тоткарлап торырга минем генә көчтән килмәячәк. Алар икәү, җитмәсә, миңа караганда шактый өлкәннәр, гәүдәгә дә тәмам җитеп җиткән егетләр. Ә Акимыч булса...

Нишләп соңарды соң әле болар? Минем чама буенча инде байтактан килеп җитәргә тиешләр иде. Әллә бер-бер хәлгә юлыгып, Костя хәбәрне ирештерә алмадымы икән? Юк, булмас, ан-

дый малай түгел, тешләгән җиреннән өзми калмый. Акимыч кичәге сәфәреннән кайтып җитмәгән булса... Чү! Җыена башлады түгелме соң болар?.. Әмма бинокль аша ныклабрак карагач, эчемә җан керде. Браконьерлар янәдән кармакларына суалчан тезәләр иде. Эшләрен бетергәч, бер хафасыз сәяхәтчеләр кебек, ком өстенә кызынырга яттылар. Әйтерсең шулай коенып, кызынып ял итәргә генә килгәннәр!..

Тукта! Мотоцикл тавышы ишетелә түгелме соң?.. Әйе, әйе, Акимыч мотоциклы! Мин аны үзенчә сызгырган тырылдавыннан бик яхшы таныйм. Хәзер инде миңа һичкем куркыныч түгел!

Мин аягүрә басам да кул болгыйм. Мотоцикл бишегенә менеп утыргач, шунда ук түкми-чәчми бар күргәнемне сөйләп бирергә ашыгам.

Мотоцикл тавышын ишеткәч, тегеләр кинәт пошаманга калды, күрәсең. Какча, колга буйлысы ком өстеннән кызыл теннискасын алып, кабаланып кия башлады. Икенчесе ашыга-кабалана ком өстеннән нәрсәдер җыйды, нәрсәнедер суга ыргытты.

— Бакалар! — диде Костя, бинокле аша карап.

Хәер, хәзер инде гади күзгә дә яхшы күренә иде. Мотоциклның үзләренә төбәп килгәнен күргәч, болар, күрәсең, хәйләгә керештеләр. Колга буйлысы кия башлаган теннискасын кире ташлады. Аннары кояшка карап алды да, һичнәрсә булмагандай, комлыкка сузылып ятты. Икенчесе дә аның янәшәсенә ауды.

Мотоцикл, ачулы пошкырып, браконьерларның баш очына ук килеп туктады. Акимыч, утыргычыннан төшүгә, су буена юнәлде.

— Каян килгән болар? — дип сорады ул, дулкын өстендә тирбәлгән үле бакаларга ымлап.

— Каян белик без! — диде тегеләрнең озын буйлысы.

Акимыч исә шунда ук икенче соравын бирде:

— Сез күрше авылныкымы?

— Ихтимал.

— Нәрсә ихтимал?

Акимыч тавышын күтәрмәде, әмма бу юлы аның сүзләре шактый таләпчән яңгырады.

— Әйе, күрше авылдан,— дип җавап бирде егетләрнең шул ук озын буйлысы. Күрәсең, биредә ул башрак иде. Аның юлдашы

исә — төпсәрәк гәүдәле, кара бөдрә чәчле егет хәзергә сүзгә катнашмады.

— Монда ни йомыш белән килдегез?

— Ни йомыш булсын! Су коенабыз, балык тотабыз.

— Ау коралыгыз кая?

— Әнә, кармаклар.

Шунда гына күрдек: болар без яшергән кармакларны алып, тал төбенә салып куйганнар икән.

Акимыч, нәрсәдер эзләгәндәй, арлы-бирле йөренергә кереште. Аннары кинәт тукталды да кырт борылды:

— Монда язулы такта булырга тиеш иде. Күрмәдегезме?

— Юк, күрмәдек,— диде озын егет, дорфа гына итеп. Аның тузгыган сары чәчләре маңгаена төшеп күзләрен каплый язган иде. Әйтерсең ялганлаганда күз карашын яшерү өчен үзе юри тузгыткан. Бераз гына ояла да белми, кызармый, тотлыкмый.

Без Акимычтан узып сүз катa алмыйбыз. Эшне бозып куюың бар! Акимыч исә, миңа калса, никтер һаман вак-төяк, кирәксез сораулар гына бирә. Тезмә кармаклары кайда икәнне беләбез ләбаса! Үгезне мөгезеннән каптырып аласы иде. Кармакларын тартып чыгарсаң, җинаятьләрен танымый хәлләре юк. Безнеке түгел, теге-бу дип тарткалаша башласалар, дәлилгә үле бакалар бар.

— Ә хәзер киенегез,— дип боерды Акимыч.

Монысы тагын нигә кирәк булгандыр! Болай сузса, әбәткә кадәр дә очына чыга алмабыз...

— Киенегез, киен,— дип кабатлады Акимыч.— Менә шула-ай. Инде әйтегез, сөйләгән бөтен сүзләрегез дә дөресме?

Егетләр бер-беренә карашып алдылар. Әлеге көтелмәгән сорау аларны бераз каушатып җибәрсә дә, сиздермәскә тырыштылар, икесе беравыздан мыгырданып куйдылар:

— Дөрес. Барысы да...

— Дөрес түгел! — дип кырт кисте Акимыч.— Дөресен менә хәзер без әйтербез.

Ул озын буйлы егеткә якын ук килеп, аның йөзенә текәлде:

— Син Шавалиха оныгы. Шулаймы?

— Ихтимал.

— Тагын ихтимал! Нәрсә ихтимал?

— Сүзгә бәйләнмәгез! — дип йөзен читкә борды Шавалиха оныгы.

Акимыч исә аңа тын алырга да ирек бирмәде:

— Бакалар синең эшме? Ие, синең эш. Үз пычрагыңны яшерер өчен аларны суга аттың, шулаймы? Кулың гына түгел, күңелең дә пычрак синең, егетем. Ә балык яклары ничегрәк? Безгә шунысы да мәгълүм: моңа кадәр ике авылда ике күлне корыттың инде син. Хәзер менә бу күлгә иyләнгәнсең, күңелсез булмасын өчен, үзеңә иш тә тапкансың икән.

Шавалиха оныгының йөзе чалшайды, күзләрендә әшәке әрсезлек очкыннары кабынды.

— Син миңа тимер читлек корамаларга мәтәшәсең, абзыкай! — диде ул Акимычка.— Юк, барып чыкмас, булдыра алмассың!

Икенче егет әле һаман бөтенләй диярлек сүзгә катнашмый иде. Акимыч аның янына килде:

— Җитәр, булмаса, төкер авызыңа капкан каз маен!

Егет дәшмәде, тик башын иеп, йөзен читкә борды.

— Ярый, хуп! Үзегезгә үпкәләрсез,— диде Акимыч.— Әллә акылга килерсезме дигән идем.— Ул, мотоцикл бишегеннән планшетын алып, арткы утыргычына утырды. Ягез, алайса, тиешенчә итеп акт төзик.

Ниһаять, безгә дә чират җитте.

— Ну, егетләр,— диде Акимыч.— Әйдә, нинди дәлилләр китерә аласыз?

Шуны гына көтеп торган Костя кесәсеннән калай банка тартып чыгарды. Анда без тапкан ике төпчек һәм кеда, сандалет эзләренең төгәл өлгесе сызылган кәгазь саклана иде.

Акимыч, банканы Костя кулыннан алып, браконьерларга таба борылды.

— Менә монда папирос төпчекләре,— дип, банка капкачына чирткәләде ул.— Нинди төпчек, дисеңме? Син тарткан төпчекләр. «Казбек» дип атала.— Акимыч, Костяның иңеннән тотып, үз янынарак әйдәде, аның кесәсеннән шариклы ручкасын тартып чыгарды:

— Менә бу егет, менә шушы куллары, шушы ручкасы белән браконьерларның кеда, сандалет эзләрен сызып алган. Алар исә хәзерге минутта сезнең тәпидә. Язулы такта да сезнең эш. Ничек суырып алганыгызны шушы ике эзтабар менә шушы бинокльдән үз күзләре белән карап, күзәтеп торган. Ничек соң, күңелегезгә хуш килмәде, алайса, кисәтү язуы, ие, ие, бака үтерүдән рәхәт табасыз шул сез. Әйтәсе дә юк, шәп шөгыль!.. Шушы

ук бинокль аша шушы ук эзтабарлар сезнең ничек итеп тезмә кармак салганны, нинди ысул белән балык тотканны да күреп торганнар. Балыкларыгыз хәзер куканда, камыш төбендә. Саплы кармакларыгыз үзегезнеке түгел, аны хуҗаларына кайтарып бирерсез. Дөрес, сөкә үзегезнеке. Аны актка теркәрбез.

Бу сүзләрне ишеткәч, Шавалиха оныгының юлдашы кинәт көрсенеп куйды. Аның куе бөдрә чәчле башы тагын да түбәнрәк иелде.

Тирә-як тып-тын калды. Әкрен генә чайкалган дулкын су өстендә йөзгән үле бакаларны яр читенә этеп китерде. Әйтерсең ул әшәке җинаятьнең тагын бер дәлилен безгә күрсәтергә тырыша, табигать корткычларына каршы аяусыз көрәшергә өнди иде.

АЛТЫНКАЙ

Оля белән Лена икесе дә бишенчедә, бер үк класста укыйлар, бер үк йортта яшиләр. Хәтта ишекләре дә бер үк коридорга ачыла, кухнялары да уртак. Дәресләрен дә бергә әзерлиләр, мәктәпкә бергә йөриләр, бер үк партада утыралар.

Кыскасы, агылай белән тагылай.

Һәм кинәт, һич көтмәгәндә, болар арасыннан салкын җил искәндәй булды.

Ни сәбәпле, дисезме? Менә, тыңлагыз.

Оляның Алтынкай исемле кечкенә генә эте бар. Килде-китте урам көчеге түгел, өйдә яшн торган затлы эт, назлы эт. Коңгырт-сары төстә. Тәпиләре, буяу савытына тыгып алгандай, кап-кара. Кәкрәйтеп сыртына салган фырт койрыгы да шулай ук чем-кара. Күргән бер кеше сокланмый калмый үзенә: «Карасана бу кыбырсыкны! Алтын кебек елкылдый!..»

Шуңа күрә исемен Алтынкай дип куштылар.

Алтынкай Оляны ярты сүздән аңлый, һәр кушканын үтәргә атлыгып, ашкынып тора. Әмма теләсә кемнең мактавына, төче-

ләнеп сырт сыйпавына һич тә исе китми, тик кәкре койрыгын гына селкеткәләп куя. Янәсе, рәхмәт инде яхшы сүзеңә, ишеткәнем бар!..

Әгәр Оля каядыр китсә, Алтынкай коридорда өй саклап кала. Ул юкка-барга теш ыржайтмый, урам көчекләре кебек, теләсә кемгә ләң-ләң өрми, үз дәрәҗәсен белеп, ишек төбендә, йоклагандай, тып-тын ята. Әмма ул һәрвакыт уяу: ара-тирә сыңар күзен генә ачып, тирә-ягын күзәтә, колагын торгызып, тыңланып куя.

Ленаның исә Һарун исемле песәе бар. Йөнтәс йонлы, шактый тәкәббер кыяфәтле асыл зат бохар мәчесе.

Һарун озаклап-озаклап, киерелә-сузыла, мамык мендәр өстендә ятарга ярата. Кемдер берәү килеп колак артын кашыса, мыр-р-мыр-р мырылдарга керешә, сыртын дугаландырып сыйпалана, иркәләнә. Карыны ачса, тотам да калмыйча, Лена артыннан йөри, игътибар итүче булмаса, яман әче тавыш белән мияулый, сөт сорый, ит сорый, чи балык таптыра. Сораганын табып бирмәсәң, хет колакларыңны томала!

Көчекне дә, мәчене дә кызларга бер үк вакытта әти-әниләре бүләк иткән иде. Шуннан бирле алар һәрберсе үз бүлмәсендә, үз хуҗалары янында рәхәт, ваемсыз гомер кичерә. Кич булса, йоклау аерым, ә иртән таң атса, коридорда гел бергә. Анда инде пыр тузып куышырга да, тере йомгактай тәгәрәшеп уйнарга да урын иркен.

Кайчак Алтынкай Оляның йомшак башмагын яки сыңар колаклы иске уенчык куянын табып ала да, әй китә коридор буенча шуны сөйрәп! Бәхет кошы тоткан диярсең! Ә мәче явыз каядыр шул тирәдә генә посып тора, кинәт кенә уктай атылып чыга да, «эһ» дигән арада уенчыкны эләктереп кача.

Шул рәвешле уйнап, котырынып алгач, бергә ятып йоклаган чаклары да була.

Алтынкай, үзе кечкенә булса да, кырык төрле һөнәр белә.

— Утыр әле яннарыма! — дип, идән сайгагына тибеп куя Оля.

Алтынкай шунда ук арт аякларына утыра да, алгы тәпиләрен еш-еш селкергә керешә. Әйтерсең чебен куа!

— Нәрсә чәбәләнәсең? Тик утыр, үрә кат! — дип боера Оля.

Алтынкай, шәм кебек, төп-төз катып кала. Андый чакта аңа

дәшмә дә, кагылма да инде, борылып та карамас, колак очын да селкетмәс. Түм-түгәрәк яшькелт күзләрендә генә наян чаткылар сикерешер. Ягъни мәсәлән, уен икән, уен булсын, хәрәмләшмә, шартын китереп уйна.

Мәктәптән кайтканда Оля уен белән мавыгып китсә, Алтынкай аның сумкасын саклап утыра, хуҗасы кушса, китереп тә бирә. Куйган хезмәте өчен күчтәнәч-фәлән теләнми, назлап-иркәләп башыннан сыйпасаң, шуңа бик канәгать.

Мәченең исә һичбер төрле һөнәре юк. Ул, нәрсәдер өмет итеп, теләсә кемгә ялагайлана. Якты чырай күрсәтсәң, шунда ук алдыңа сикереп менә, ышкына, боргалана. Аннары бик җайлап кына бөгәрләнеп ята да күзләрен йома. Әгәр куып төшермәсәң, мыр-мыр-р килеп, сәгатьләр буе шулай ятарга риза. Шуңа күрә Оля аны Мырмырый дип атый. Моңа Ленаның хәтере кала.

— Теләсә нинди йомыш үтәп йөрергә, йолкыш көчек түгел ул минем Һарун. Иеме, Һарун? Әнә нинди ягымлы мырылдый белә бит ул! Тавышы да үзе кебек йомшак бәрхет!

— Ә минемчә, ул — хөрәсән ялкавы,— дип ирештерә дустын Оля.— Житмәсә, теләсә кемгә тигәнәк кебек ябыша, өнәрсез.

Шул рәвешле көннәр, айлар узды. Үскән саен эт белән мәче арасындагы дуслык суына барды.

Хуҗасы белән кайдадыр йөреп кайтсалар, Алтынкай коридор почмагына җәелгән иске палас өстенә менеп ята. Рөхсәтсез ник бер адым атласын! Пырдымсыз сабый чаклары узган саен, хуҗасына тугрылык хисе дә бермә-бер арта бара. Чакырган һәр кешегә иярми, теләсә кем кулыннан азык алмый, һәрчак тәмле ризык исе бөркеп торган кухня ишегенә дә игътибар итмәскә тырыша.

Һарун исә биредә үзен бөтен йортка хуҗа итеп сизә. Ашыкмый гына, вәкарь белән атлап, коридор буенча арлы-бирле йөри, һәрнәрсәне барлап, иснәп чыга, теләсә кайчан кухняга кереп иснәнә. Хуҗалардан берәү дә булмаган чакта, анда ул үзе баш, үзе түш. Алтынкай исә аның өчен әллә бар, әллә юк, бөтенләй күрмәмешкә салына. Әйе, ник әле ул аның белән ваксынып торсын! Аның ишеләр урамда һәр капка асты саен. Бәяләре — базар көнне поты бер тиен!

— Үз кадерен белә ул минем Һарун,— дип мактана кайчак Лена.

— Мактама инде шул мырылдыгыңны,— дип көлә Оля.— Аңа мин Алтынкайның сыңар төген дә бирмәс идем. Күптән беләм аның нинди икәнен.

— Йә, әйт. Әйтеп бетер — нинди? — дип, кашын җыера Лена.

— Дөресен әйткәнгә ник ачуың килә? Үзең дә беләсең ләбаса...

Шундый бер сөйләшүдән соң Лена, кырт борылып, ишекне каты ябып, үз бүлмәсенә кереп китте. Ә икенче көнне, Оляны коридорда туктатып, йөзенә бәргәндәй әйтеп салды:

— Синең Алтынкаең — карак!

— Ни сөйлисең син, Лена?!

— Ишеткәнеңне сөйлим. Күптән сизеп йөрим инде мин аның андый мутлыгын. Әйтмәгәч тә...

Ишек төбендә тын гына яткан Алтынкай, бу сүзләрне аңлагандай, кинәт калтыранып куйды, Ленага карамаска тырышып, читкә борылды. Тик сырт йоннары гына кабарып үрә басты. Ул менә-менә өреп җибәрер, нахак яла ягучыга ташланыр кебек иде.

— Ә-ә, шулаймы? Дөресен әйткәнгә кабарынасыңмы, карак мүчкә! — дип дәвам итте Лена.

Оля исә бу минутта тәмам телсез калган иде. Күзләрен зур ачып, ни әйтергә белмичә аптырап тора бирде. Ә Лена аның саен азынды:

— Бик беләсең килсә, кухняда иснәнә ул синең кадерле Алтынкаең!

— Сөйләмә юкны, сөйләмә! — диде Оля, еларга җитешеп.— Аның өчен ант итә алам. Андый түгел ул Алтынкай!..

— Ә мин әйтәм, шундый!

— Алай бик белсәң, ник барысын да әйтеп бирмисең? Ник бушка тел тегермәне әйләндерәсең?

— Ярар, алайса, үз күзләрең белән күрерсең. Хәзер үк. Бүген үк...

Лена кереп китүгә, Оля этен чакырды:

— Алтынкай! Кил әле! Кил!

Эт нечкә генә тавыш белән чинап куйды, әкрен генә атлап, Оля артыннан бүлмәгә керде. Ул никтер элеккечә сөенеп сикергәләми, ничектер боек күренә. Әйтерсең чыннан да хуҗасы алдында бер-бер гаебе бар. Әйтерсең ул шулай башын иеп,

гаебе өчен җәза биргәннәреп кетә. Ләкин Оля аңа ышана иде.

— Син акыллы бит, иеме, Алтынкай,— дип, башыннан сыйпады ул аны.— Акыллы бит, иеме? Лена ялгыша бит, иеме?

Җавап итеп эт янәдән әкрен генә чинап куйды, ышанычы өчен рәхмәт әйткәндәй, кытыршы теле белән хуҗасының кулын ялап алды. Ләкин Оля биргән төче коймакны теләр-теләмәс кенә ашады. Әйтерсең тамак туклыгы өчен түгел, рәхимле хуҗасының күңеле кырылмасын өчен генә ихтыярсыздан ашый иде. Башка вакытта уенга ашкынып тора торган шаян көчек бу юлы хуҗасы белән уйнарга да теләмәде. Аңлады Оля: этнең кәефе тәмам кырылган иде.

Ләкин, ишекне ачып, коридорга чыгару белән, Алтынкай ярсып-ярсып өрә башлады. Бусы да сәер тоелды, чөнки Алтынкайның һичбер вакытта юкка-барга сөрән сала торган гадәте юк иде.

Оля, ишекне әз генә ачып, коридорга бакты: беркем дә юк. Ә Алтынкай кухня ишегенә карап өрә... һәм кинәт шунда... кухнядан Һарун атылып чыкты. Чыкты да, атылып-бәрелеп, чүп-чар чиләкләре арасында гаип булды.

Бу хәлгә артык игътибар итмәстәнн, Оля дәресләрен карарга утырды. Әмма озак та үтмәде, шактый каты итеп ишек шакыдылар. Аннары, рөхсәт тә сорамыйча, Лена килеп керде. Аның йөзе чытылган, күзләрендә зәһәр чаткылар чагыла иде.

— Әнә, күр мактаулы көчегеңнең һөнәрен! — диде ул, ачулы тавыш белән.— Кибеткә сөт алырга гына чыккан идем, ә ул ачкак минем кухня өстәлендәге колбасаны сосып бетергән!

— Юкны сөйлисең, Лена,— диде Оля, тыныч булырга тырышып.— Алтынкай ул ачка үлсә дә кухнядагы әйбер-карага ягылмас.

— Ишеткән бар инде андый әкиятеңне! — дип кырт кисте Лена.— Алайса, кая киткән ул колбаса? Албасты алмагандыр бит аны!

— Албасты түгел, үзеңнең мәчең...

Оля әле генә үз күзе белән күргәннәрне төкми-чәчми сөйләп бирде. Ләкин Ленаның үз туксаны туксан иде.

— Шуннан ни булган? Син аның колбаса ашаганын күрмә-

гәнсең бит! — дип, аның саен кыза барды ул.— Әллә аны коридорга да чыгармас идеңме? Авызыңны үлчәп ач, тотылмаган — карак түгел!

— Алайса, Алтынкайга яла якма!

Бу көнне ахирәт дуслар, гомерлек дошманнар кебек, дөм орынып йөрделәр. Берсе дә башлап тел ачарга теләмәде. Һәрберсе күңеленнән иптәшен гаепли, үзен хаклы саный иде.

Әмма болай күркә кебек кабарынып йөрү берсенә дә рәхәт түгел. Күңелдә таш яткан кебек, ниндидер авырлык баса. Хәтта яз кояшының ягымлы нурлары да җылытмый, куандырмый.

Икенче көнне инде алар артык түзмәделәр, коридорда очрашу белән сөйләшергә керештеләр һәм тиз арада килешеп тә киттеләр. Күңелдә калмасын өчен, барысын да азагынча ачыкларга булдылар.

— Әйдә, болай итик,— диде Лена.— Кичәге кебек, өстәлдә колбаса кисәге калдырыйк...

— Әйдә, әйдә! — дип элеп алды Оля.— Үзебез минем бүлмәдә качып торыйк. Кирәк вакытта Алтынкай хәбәр итәр. Чыгар Һаруныңны.

...Киеренке тынлык урнашты. Шактый вакыт һичбер тавыштын ишетелмәде. Инде түземе төкәнә башлаган Лена иптәшенә дәште:

— Әйдә, чыгып карыйк әле...

Ләкин үз сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, коридорда Алтынкайның үртәлеп ырылдаганы ишетелде. Һәм ул шунда ук ярсып-ярсып өрә дә башлады. Оля белән Лена коридорга, аннан кухня ягына ашыктылар. Өстәлдә колбаса юк иде... Лenaның мәчесе дә каядыр китеп югалган иде.

Эзләргә керештеләр. Өстәл асларын, шкафларны карап чыктылар, хәтта плитә эчен дә тентеделәр. Юк!

Карасалар, Һарун кухня өстәле белән стена арасындагы тар гына аралыкка кереп поскан икән.

Көч-хәл белән тартып чыгардылар. Ә мәкерле мәче һич кенә дә чыгарга теләми, теше-тырнагы белән каршы тора. Сырт йоннары үрә баскан, күзләре ут яна. Үзе усалланып мырылдый, ә авызында... колбаса кисәге!..

Карап-карап торды да Лена, мәчесен кырыс кына читкә этәрде:

— Бар, кереп кит өйгә, юньсез нәмәстә!

Аннары, бераз вакыт идәндә тып-тын гына башын иеп утырды да, торып, Алтынкай яткан почмакка юнәлде, иркәләп-назлап, көчекне сыйпарга кереште. Үзе көчекне иркәли, ә үзе яшь тулган күзләрен дусты Оляга күрсәтмәскә тырышып, йөзен читкә бора:

— Үпкәләмә миңа, Алтынкай... Йә, килешик... Юкка рәнҗеткәнмен сине... Юкка, бер дә гаепсезгә...

Аның бу үкенү сүзләре Алтынкайга гына түгел, җан дусты Оляга да әйтелгән иде, әлбәттә.

КӨМЕШ УТРАУ КОШЫ

Ишекне ачып җибәрүгә, Валька бер мәлгә тәмам өнсез калды: бар дөнья ап-ак. Әле кичә генә күзгә сагыштан саргаеп утырган авыл өянкеләрен, куакларны, ихата түрендәге әрем сабакларын, хәтта каралты-кура стеналарын — һәммәсен көмеш бәс сарган иде.

Малай ашык-пошык кына капкалап чыкты да күрше йортның тәрәзәсен шакыды:

— Юрка! Йокы чүлмәге! Әйдә, җыен!

Шуны гына көтеп торгандай, өйалды ишеге шар ачылып китте, ләкин баскычка Юрка түгел, аның сеңлесе Лена чыгып басты.

— Китте инде ул,— диде Лена, мәктәп ягына кул изәп.

— Ә нишләп миңа эндәшмәде?

Лenaның авызы җырылды:

— Белмим инде анысын. Баргач, үзеннән сорарсың. Туңасың бит, шәүләгән! Бар, кереп кит тизрәк!

Әмма кызый кереп китәргә ашыкмады, кырпак сарган баскыч сайгагында ялантәпиеннән юеш эзләр калдырып, бер урында тыпырдарга кереште. Валька аның белән артык сүз озайтып тормады, юл аркылы чыкты да, кыршылган иске сумкасын җилкәсенә чөеп, күл буена төшә торган сукмакка юнәлде.

— Кая барасың? Әллә адаштыңмы? — дип чыркылдады Лена.

Валька борылып та карамады. Аның башына үзенчә бик шәп фикер килгән иде. Әйе! Әгәр күл туңган булса, боз өстеннән кистереп кенә чыгасың да, мәктәпкә Юркадан алда барып утырасың. Күзе шар булсын әле мактанчыкның!

Кичә алар бераз гына әйткәләшеп алганнар иде. Дөрес, алай артык зурдан кубып түгел...

Гадәтенчә, Юрка көннең-көнендә йокысыннан айный алмый ята, еш кына дәрескә дә соңара. Беркөнне шулай өченче дәрес башлангач кына килеп керде. Бөтен класс күтәрелеп көлде үзеннән. Шул вакыйгадан соң Валька дустына ярдәм итмәкче булган иде. Әмма бу эш алай җиңел булып чыкмады. Ул хөрәсәннең торып юынганын, мыштыр-мыштыр киенгәнен көтә-көтә көт буласың. Шуның аркасында кайчак үзең дә дәрескә соңга каласың.

Тәмам түземе төкәнгәч, кичә иртән күңелендәгене әйтеп салды Валька:

— Җитте сиңа, үз җаеңны үзең кара! Моннан ары сине көтеп утырасым юк!

— Көтмә, алай бик читен булса. Мин сиңа көтү сарыгы түгел,— дип, авызын бүлтәйтте Юрка.

— Алайса, бер йокыңа хуҗа була бел. Иртәрәк торсаң, мине дә уятырсың...

Бу кадәресе Юркага кулай түгел иде, әлбәттә. Менә бүген шуның үчен алмакчы булгандыр, күрәсең. Сеңлесе уяткандыр, тәгаен, әнә бит ничек авыз җырып калды. Ярый, карап карарбыз...

Үзе уйлап тапкан хәйләгә куанып, Валька елмаеп куйды: «Күрербез, боз гына тотсын!»

Әмма дәрескә соңарсаң... Ну, рәхәтләнеп көлә инде ул чакта. Үзен-үзе белмәс, йоклап калган, дип бөтен класска сөрән салыр.

Бәхеткә каршы, күл өсте боз белән капланган иде. Көзге кебек шоп-шома, тик яр читләре генә, көрпә кар сипкәндәй аксылланып, кабалакланып ята.

Малай, сак кына басып, күл өстенә керде, бозның нык-

лыгын сынап, аягы белән тибеп-тибеп карады, аннары бөтен гәүдәсе белән сикереп куйды. Бер сикерде, ике, өч...

Күзгә боз күзгә калынлыгы булса да..., дип юкка әйтмиләр, күрәсең, әйбәт тота иде. Бер төн эчендә шундый тамаша!

Валька, чаңгыда йөргән кебек, аякларын алмаш-тилмәш шудырып, һаман эчкәрәк керде, ике аягында шуып та китте...

Кырлар ягыннан җиңелчә генә җил исеп куйды, күл өстендә эз-эз ясап, җәяүле буран себерде... Шунда кинәт... Мылтык аткандай бөтен тәнне сискәндереп, боз шартлады. Тармак-тармак эзләре әллә кайларга, аргы як ярларга таба сузылып китте.

Валька, шомланып, бер мәлгә туктап калды, әмма шунда ук хәтеренә төште: боз чатнаган урында озак торырга ярамый. Җитмәсә, бу тирәдә күлнең иң тирән җире, бозы да әллә нинди... яшькелт-кара пыяла төсендә. Күренеп үк тора — аста төпсез тирәнлек. Җәй көне малайлардан берәү дә болай эчкәре йөзеп керергә батырчылык итми, көймә белән кереп үлчәсәң, төпкә дилбегә җитми, имеш.

Валька сулгарак каерды. Әмма, бер-ике атлауга ук, арка тамырларын чымырдатып, янәдән зәһәр чытырдау яңгырады, янәдән аяк астында тармак-тармак чатнау эзләре хасил булды.

— Куркырлык нәрсә юк...— дип үз-үзенә куәт бирергә тырышты малай.— Шулай шартламаса, бозның юка икәнлеген каян чамалар идең әле?!

Ул, сак кына басып, тагын сулгарак, шул тарафта күренгән кечкенә генә утрауга таба атлады.

Валька хәзер бераз гына үкенә дә иде инде. Юрканы кызык итәм дип, ни пычагыма килеп керде соң әле ул мондый өрфиядәй юка боз өстенә! Алдан барып җитә, имеш! Сулга каерган саен мәктәпкә ара ераклаша гына бара.

Аның каравы, утрауга якынлашкан саен, боз әкрен-әкрен аксыл төскә керә. Димәк, биредә артык тирән түгел. Инде шартлау тавышлары да сирәгәйде кебек. Авылдан караганда аксыл томан эчендә чак-чак кына күренгән кечкенә утрау хәзер кул сузымында гына, ә авыл каралтылары, киресенчә, томан пәрдәсенә төренгән.

Утрауга килеп чыккач, Валька иркен сулап, яр читендә яткан черек агач кәүсәсе өстенә утырды, тирләп чыккан маңгаен бишмәт җиңе белән сөртеп алды.

Уйлап карасаң, аның хәле шактый мөшкел иде. Кем әйтмешли, ни алга, ни артка, аркылы чыгыйм дисәң дә, тәртәне кирегә борсаң да куркыныч...

Үзенең хәленә ачыклык кертергә теләгәндәй, Валька тирәягына күз йөртеп алды. Утрау өстендә, ярдан биш-алты гына адымда сирәк таллык, яр буе камышлыгы шул талларга ук барып тоташа. Бая гына исеп куйган зәгыйфь җил әйтерсең монда бөтенләй кагылмаган — тал ботакларын сарган көмеш бәснең бөртеге дә коелмаган, камыш сабаклары да, утрау өстендәге куе үлән дә ап-ак. Дөнья саф, дөнья пакь... Күңелдә әйтепсөйләп биргесез назлы тынычлык урнаша. Сихри тынлык! Куркырга, шомланырга һичбер сәбәп юк кебек.

— Көмеш утрау! — дип, сокланып елмайды Валька. Һәм шунда аның башына бик кызыклы фикер килде: серле утрау турында китап укыганы бар аның. Хәзинәләр утравы хакында да. Ә менә көмеш утрау турысында һичкайда язылмаган. Бу утрауга моннан ары Көмеш утрау дигән исем бирергә кирәк! Көмеш утрау! Мәшһүр сәяхәтче Валька Семенов ачкан утрау!..

Шунда кинәт..., малайның татлы хыялларын бүлеп, куе камышлар арасында нәрсәдер кыштырдап куйды.

Нәрсә булыр ул?

Хәтта җәйге эссе көннәрдә дә бу сазламык утрауга һичкем чыгып йөрми, биредә тик бихисап чебен-черки үзе генә хакимлек итә. Тукталса, тик комар балыкчылар гына тукталып китә, аларның да көймәсе булганнары гына. Ә андыйлар авылда бармак белән генә санарлык. Көз көне сирәк-мирәк, кыр үрдәкләре җылы якларга очар алдыннан, утрау камышлары арасында аучылар качып тора. Әмма хәзер ул вакытлар күптән узган, киек казлар да инде үзләренең ерак сәфәрләренә чыкканнар...

Әллә соң су күселәре йөриме?

Алай дисәң, күселәр сазламык урынны өнәмиләр, өн казу, оя кору өчен корырак, калкурак ярны сайлыйлар. Төлке, бүре ише ерткыч җанварның исә бу тирәдә эзе дә булганы юк.

Малай эченнән шулай уйласа да, әлеге кыштырдау тавышлары янәдән кабатлангач, бераз шомланып та куйды. Биредә ул бит япа-ялгызы. Авыл әнә нинди еракта калган, хәвеф-хәтәр булса, кычкырсаң, тавышыңны ишетүче булмас...

Шул арада ерак офыктагы тезмә таулар артыннан кызарып кына кояш күтәрелде, бөтен тирә-якны каплап, дөньяга тылсым-

лы төс биреп торган сыек томан таралып юкка чыкты. Димәк, вакыт Валька уйлаганча алай бик иртә түгел — мәктәптә дәресләр күптән башланган булыр. Ашыктың ни хәзер, ашыкмадың ни, калган көтү калган...

Кояш күренүгә, шик-шөбһәләр дә иртәнге томан кебек эреп таралды. Валька, аяк астында яткан агач кайрысын алып, кыштырдау тавышы ишетелгән юнәлешкә томырды. Кайры кисәге барып төшүгә, шул тирәдә тагын нидер кыштырдады, үлән сабакларыннан ак бәс коелды. Димәк, нииндидер җан иясе, хәвефхәтәр барлыгын тоеп, шунда посып утыра.

Малай, кызыксынып, утырган урыныннан торды да, чыпчык аулаган мәче кебек сак кына басып, шул юнәлешкә атлады. Ләкин өч-дүрт адым да китеп өлгермәде, куе үләннәр дәррәү хәрәкәткә килде, камыш сабакларын сарган көмеш бәс пыранзаран коелып, әлеге җәнлекнең кайсы тарафка тайпылганын аермачык күрсәтеп торалар иде. Әйе, хәйләкәр җәнлек һич кенә дә ачык урынга чыгарга теләми, ничек тә утрау эченәрәк шыларга тырыша.

Валька, аның юлына аркылы төшәргә теләп, утрауның каршы як ярында үскән тал-тирәкләр ягына йөгерде. Әмма җәнлек, һич көтмәгәндә кырт борылып, әле генә Валька утырган черек агач кәүсәсе ягына тайпылды. Ә анда — муен тиңентен озын камышлык, барып ирешсә, койрык очын да күрмәссең!..

Малайның юраганы юш килде, киек җәнлек аннан җитезрәк булып чыкты. Камышлар тагын бераз гына кыймшангалап куйдылар да... тирә-як тып-тын булып калды. Ләкин малайның күңелендә борынгы сунарчы бабайлар комарлыгы уянып өлгергән иде инде. Бактың исә, әлеге камышлык артык еракка сузылмаган икән ләбаса, бар булганы ун-унбиш адымнар чамасы; аннан ары, сирәк кенә таллыкларны узуга, шәп-шәрә ялан кыр, аннары көзгедәй шома боз өсте...

И-их, шушында хәзер әпрән колак Алабае үз янында булсачы! Сөреп кенә чыгарыр иде тегеләй!

Валька, бераз гына уйланып торда да, тирәклеккә барып, алагаем озын тал ботагы сындырып алды, шул ботак белән кизәнеп-кизәнеп, камыш ботакларын кыйнарга кереште. Һәм аның тырышлыгы бушка китмәде, әлеге шау-шудан коты очкан бичара киек камышлар ешлыгыннан ялан кырга атылып чыкты.

Аны күрүгә Валька, ачкан авызын ябарга онытып, бер мәлгә тәмам аптырап калды. Чөнки аның алдында күсе дә, төлке

киек тә түгел, ә гап-гади йолкыш үрдәк калтыранып утыра иде.

Гаҗәп! Каян килеп чыккан бирегә бу мәхлук? Җәйге эссе көннәрдәге кебек, койрыгын күккә чөеп, җылы сазлыкта казынмакчы булганмы? Симез-симез чукмарбашлар аулап сыйланырмын дип саташканмы? Әллә көмеш утрауның тылсымлы матурлыгы тартып китергәнме үзен?

Ни генә булмасын, биредә бу зәгыйфь кошның ялгызын калдырып китәргә малайның күңеле кушмады. Җан иясе, тереклек азгыны ләбаса!

— Үтти-үтти! — дип, ягымлы тавыш белән үрдәккә дәште ул.— Әйдә, авылга кайтабыз, монда ялгызың калсаң, катып үләрсең бит, тиле-миле! Өеңдә иптәшләрең көтәдер, хуҗа әбиең бәрәңге боткасы изеп чыгаргандыр...

Шул рәвешле үгетли-үгетли, үрдәккә якынлашты Валька. Тик, гаҗәпкә каршы, бу йолкыш шактый елгыр булып чыкты. Ул, кинәт кенә читкә тайпылып, һавага очарга җилпенә башлады.

Валька шунда гына абайлап алды: йорт үрдәге түгел иде бу, табигать кочагында үскән ирекле киек кош иде. Ләкин ул, ничек кенә бәргәләнмәсен, һавага күтәрелә алмый: бер канаты гарип иде. Яралы иде, күрәсең. Хуҗасы да юк аның, торыр оясы да... Туганнары да инде күптән җылы якларга китеп барган, ә бу, нәүмиз булып, шушы салкын утрауда ялгызы аерылып калган...

Аучылардан ишеткәне бар Вальканың: бу төр үрдәкләр Каспий диңгезе култыкларында кышлыйлар, имеш. Менә язлар җитәр, барча киек кошлар, кыйгач-кыйгач төркемнәр булып, туган якларга кайтырлар. Өйгә алып тәрбияләсәң, язга кадәр, бәлки, бу нәүмизнең дә каерылган канаты төзәлер иде...

— Әйдә, үтти, әйдә, курыкма. Язга кадәр бездә, җылы абзарда торырсың!..

Әмма, ничек кенә ягымлы дәшмәсен, киек кош адәми затның телен белми, күңелен аңламый иде. Үлем кораллы тоткан бәндәне бер күргән — берәгәйле күргән, очар канатыннан мәхрүм калган. Аңа хәзер барлык адәми затлар бердәй рәхимсез — һәммәсе ике аяклы ерткыч! Шуңа күрә ул хәзер уттан качкандай бәргәләнә, талпына. Болай кыйланса, соңгы сыңар канатын да сындыруы ихтимал.

Бая, пыр тузып көмеш утрау камышлыгында билгесез киек

артыннан чапканда, сунарчылык дәртенә бирелеп, һичнәрсә уйламаган иде малай. Менә, көтмәгәндә башына хафа төште. Нишләтергә соң моны?.. Тиздән кар ятар, бөтен җир, әз-мәз азык булырлык бөтен үләннәр күмелеп калыр. Кош исен сизеп, төлкефәлән дә бирегә сугылмагае. Әллә инде аучы Ерофейга кайтып әйтергәме? Хәер, аңа әйтүдән ни файда? Мылтыгын алып килер дә шунда ук атып үтерер. Ул зөбаныйга ике дөнья — бер морҗа. Шуңа күрә авылда һичкем яратмый аны. Юк, бу ятим кошны ничек тә авылга алып кайтырга кирәк.

Ләкин үрдәк әле уңга, әле сулга ташлана, ни күрәсен белми, һаман камышлыкка каера. Валька исә, тал ботагы белән селтәнеп, һәр очракта аның юлын бүлә...

Ниһаять, шул рәвешле кысрыклап, үрдәкне шәрә боз өстенә төшәргә мәҗбүр итте.

Ләкин зәгыйфь кош боз өстендә аягында басып тора алмый, атлаган саен таеп егыла, аннары янәдән тора, авырткан канатын көч-хәл белән сөйрәп, алга сөрлегә.

...Авыл караltыларына якынлашкан саен, үрдәк тагын да яманрак тынгысызлана башлады. Ярга килеп чыгуга, үзендә ниндидер гайре табигый көч табып, сукмак буенда үскән куе әрем сабаклары арасына чумды.

Авыл башындагы пар каен төбендә Лена басып тора иде.

— Җибәрмә, Ленка, җибәрмә ул якка! Каршысына төш! — дип кычкырды Валька.

— Кем үрдәген куып йөрисең болай? — дип чыркылдады кызый. Аннары, нәрсәдер исенә төшкәндәй, капыл сорап куйды:

— Нәстә син мәктәптә түгел әле?

— Нәстә-ә... Кәбестә-ә! — дип үчекләде аны Валька. — Кыр үрдәге бу, бик беләсең килсә. Булыш, диләр сиңа! Ач капканы! Нәрсә мыштырдыйсың инде, безнең капканы ачканың юкмы әллә? Келәсен күтәр, пешмәгән!

Капканы ачып куйгач, Лена да үрдәк куарга кереште. Шул рәвешле икәүләп ике яктан кысрыклый торгач, ниһаять, үрдәкне капкага куып керттеләр. Моңа кадәр һичбер өн-аваз чыгармаган киек кош, үзенең тоткынлыкта икәнен сизенепме, әрнүле тавыш белән инәлеп кычкыра башлады. Аны сарайга куып кертергә тырышып, Валька тәмам тирләп-пеште. Бу киребеткән кошка хәзер аның хәтере калды, җен ачулары чыкты. Җитмәсә, шунда Лена канга тоз сибеп тора:

— Каян алдың бу йолкыш үрдәкне? — дип чырык-чырык көлә.

— Каенсардан!

— Нишләтәсең инде аны хәзер? Суярга симертәсеңме?

— Хәзер үк суям! Абыең белән сине кунакка чакырырмын! Бүтәкәсе — сиңа,— дип кырт кисте Валька.

Ләкин шунда үзенең болай кырыс кыйлануы үзенә үк уңайсыз тоелды. «Ярдәм иткән булып мәш килә, ә мин аңа якты чырай да күрсәтә белмим»,— дип уйлады ул. Һәм, шул дорфалыгын акларга теләп, ягымлы гына өстәп куйды:

— Канаты авырта аның, бергәләп карарбыз, яме.

Лена ризалык белдереп баш изәде дә капкага юнәлде.

Җылы өйгә кереп, җылы аш ашап алгач, малайның бөтен тәне авыраеп, рәхәт кенә оеп киткәндәй булды. Ләкин бу ваемсыз халәте аңа ничектер урынсыз сыман, оят эш сыман тоелды... Менә аның урыны җылыда, тамагы тук. Ә ул мескен кош атналар буе ризык заты капмагандыр әллә... Кыткылдык тавыклар арасында бөтенләй куркып та калгандыр...

Ул, бишмәтен җилкәсенә салып, ишегалдына чыкты. Сарай ишегенә колагын куеп, озак кына тыңлап торды: һичбер тавыш-тын ишетелми. Ишекне әз генә ачып, эчкә керде.

— Үтти! Син кайда?

Сарай эче дөм караңгы, күзгә берни күренми. Тик күз ияләнә төшкәч кенә абайлап алды: яралы кош түр почмактагы салам өеменә борынын төрткән дә... тәмам сеңгән, юк булган.

Бу тамашаны күреп, малайның йөрәге сулкылдап куйды, кошны кулына алып иркәлисе, сөясе, изүенә тыгып, үзенең тән җылысы белән җылытасы килде. Әмма, бераз гына якынлашуга, киек кош саламга тагын да ныграк елышты. Куркудан аның бөтен тәне калтырана иде кебек.

Үч иткәндәй, шунда тавыклар кытаклаша башлады. «Нинди чакырылмаган кунак?!» — дигәндәй, кызыл әтәч гайрәт чәчәргә керешге.

— Курыкма, үтти, усал түгел алар. Тими алар сиңа,— дип, үрдәкне тынычландырырга тырышты Валька.

Сарай стенасында иске каз оясы эленеп тора иде. Валька аны чөйдән алып, сак кына киек кош өстенә каплады. Бераз уйлап торганнан соң, өстендәге бишмәтен салып каплады. Әмма болай иткәч үрдәкнең тыны бетәр сыман тоелды. Каз оясының бер читен әз генә күтәрә төшеп, утын түмәре кыстырды.

Өйгә кереп, ипи кисәкләре, ботка калдыклары алып чыкты, иске табак белән су китерде. Савытларны каз оясы астына шудырып кертте дә читкәрәк китеп көтә башлады. Ләкин үрдәк азык ягына борылып та карамый иде...

Кичке якта ашыга-кабалана Юрка килеп керде.

— Лена әйтә... Валька кыр үрдәге тоткан, ди. Чынмы? Күрсәт әле! — дип кычкырды ул, керә-керешкә.

— Ашыккан ашка пешкән. Курка әле ул чит кешедән. Читлек ясагач күрсәтермен.

Бу сүзләрне ишетүгә, шунда ук Юрканың иреннәре бүлтәйде. Үпкәләргә генә тора, хөрәсән! Иртәнге этләшүе өчен үч ала дип уйламагае тагын...

Каз оясын күтәреп карауга, Валька үзе дә абайламастан кычкырып җибәрде:

— Ух-ти-и...

Бу сүзләрнең мәгънәсен Юрка үзенчә юрады:

— Ерофей аткандыр әле! — дип тәгаенләде ул шунда ук.— Аучылар да күлеп сөйли аның турында: бер үрдәк атып ала, унысын яралап калдыра, диләр. Хәсрәт сунарчы!

— Аны әйтмим әле мин. Әнә, бөтен азыгын сосып куйган!

— Ә нәрсә ашый соң ул?

— Ашата белсәң, бөтен нәрсәне...

— Ә симәнке ашармы? — дип сүзгә кушылды Лена сарай ишеге төбеннән һәм, җавап та көтеп тормастан, кәрзин чыбыклары арасыннан учлап-учлап көнбагыш коярга кереште. Тик үрдәк, куркынып, җәенке томшыгын гына селкеткәләп куйды.

Озакламый Вальканың әнисе эштән кайтты. Кыр үрдәге хакында ишеткәч, тәмам аптырап, озак кына башын чайкап торды:

— И-и, бала-бала! Бала түгел, бәладер син! Кемгә охшап бу кадәр булдың? Әле адашкан көчек алып кайта, әле чатан мәче! Гарип үрдәк җитмәгән иде шул!

— Төзәлә ул, әни... Терелә ул, менә күрерсең!

— Аккош та тотып кайт инде, булмаса. Иван дәдә поши-лар күргән, бар, аларын да куып апкайт! Кабан дуңгызлары да очрамасмы? Җәнлек базары ачарбыз. Урман өрәге булдың ләбаса!..

Ул шулай бик озак сөйләнде, бик озак зарланды, ләкин аның тавышында ачу, рәнҗү галәмәтләре сизелми иде. Валька, авыз ачып, һичбер каршы сүз әйтмәде, өйдә, бохар мәчесе

кебек, шыпырт басып йөрде, әнисенең һәр кушкан йомышына: «ярар, әни», «хәзер, әни» дип кенә торды. Әмма уенда һаман шул гарип үрдәк булды. Хәтта йокыга яткач та бик озак йоклый алмыйча, гел шуны уйлап ятты. Каян килеп чыккан икән соң ул көмеш утрауга? Канатын ничек имгәтте икән? Бәлки, чыннан да, Ерофей аткандыр. Ә бәлки... очып барганда давыл бәреп төшергәндер. Булды бит шундый хәтәр давыллар. Хәер, ул бит әвеш-тәвеш килеп йөри торган көпшәк-симез йорт үрдәге түгел, канатлары зәһәр җилләрдә чыныккан табигать кошы. Кайсы якларга китә дә кайлардан кайта икән алар бирегә? Кызганычка каршы, тәпиендә алюмин балдагы юк. Менә терелеп кенә җитсен, яз көне шундый балдакны үзе кигезеп җибәрер. Елга-күлләр боздан арчылгач, бәлки, Көмеш утрауда үз туганнары белән очрашыр. И-их-ма!..

Тукта, тышта кем сызгыра? Кем шакылдый?.. Җил чыккан түгелме соң? Әйе, зәһәр көзге җил тәрәзә капкачларын шакышокы китерә, түбә калаен дөбердәтә, морҗага килеп, әллә улый, әллә елый?.. Өй эчендә, идән сайгакларын шыгырдатып, кем йөри тагын? Әнисе түгелме соң? Торып чыкканын ничек сизми калды әле?

— И-и бала! Бәла! Тавыклар кунакчага менмәгән, шул бетәшкән кошыңнан ятсыналар... Үрдәгеңнән шулпа пешереп бирермен әле менә, ашарсың туйганчы!..

Ә Валька йокы аралаш тын гына елмая... Юк, әни. Пешермисең, әни, юри генә өркетәсең. Үзең дә тереклек җанлы син, йомшак син, рәхимле син!..

Иртәгесен Валька, берни булмагандай, мәктәпкә китте. Барышлый Юркаларга сугылды. Гаҗәпкә каршы, Юрка әллә кайчан әзерләнеп торган иде.

Мәктәптә малайның дәресе дәрес булмады, күңеле һаман-һаман кошы янында иде. Кайту белән читлек ясый башларга ниятләп, планнар корып утырды. Читлекне чоланга урнаштырырга да була; җылы да анда, тыныч та, кечкенә генә тәрәзәсеннән яктылык та җитәрлек төшә...

Дәрестән соң Юрка шахмат түгәрәгендә калды, Валька үзе генә кайтып китте. Капка төбендә аны Лена көтеп тора иде.

— Валька, үрдәгең югалды! — дип ашыга-тотлыга сөйли башлады ул. — Әниең чыгарды... Юри түгел, ашарга бирмәкче иде... Кудык, кудык... Ә ул капка астыннан чыкты да качты!

Валька артык тыңлап тормады, еларга җитешеп, туп-туры сарайга керде. Әйе! Каз оясы почмакта аунап ята, ә үрдәк — юк!

Малай сумкасын салам өстенә салып ташлады да, өйгә кереп тә тормастан, урамга атылып чыкты. Узышлый Ленага кычкырып китте:

— Әйтерсең Юркага, мин утрауга барам.

Туктаусыз чүкеч белән төйгәндәй, аның башын тик бер уй төйгечли:

— Юк, ерак китмәскә тиеш! Ничек табарга? Ничек коткарырга? Караңгы төшкәнче өлгерергә! Ул тирәдә утравы да берәү генә түгел, барысын да... Барысын да актарып чыгарга...

Күл ярына җитәрәк, аның күңеле янәдән сискәнеп-сыкранып куйды: җилкәсенә мылтык асып, икенче сукмактан Ерофей төшеп килә иде. Валька, аңа күренмичә, яр аслатып алга йөгерде.

...Көмеш утрауны бүген танырлык та түгел: төн буе котырынган рәхимсез давыл аның бриллиант бизәген талап киткән, шул кайгыдан утрау тәмам боегып, кара коелган.

— Үтти! Үтти! Син кайда? — дип кычкырды Валька һәм камышлар арасына ташланды, ниндидер агач төпләренә, түмгәкләргә абынып егылды, тагын торып йөгерде, чәнечкеле гөләп куакларына сыдырылып, киемен ертты, кулын, йөзен канатты, ләкин канны сөртеп торырга аның вакыты юк иде...

— Үтти! Үтти! Явыз кеше килә! Афәт килә сиңа. Кайда син?..

...Юк иде үрдәк. Камышлыкта да, үләннәр арасында да, таллыкта да юк иде... Ә көне нинди томса, нинди ямьсез! Тиздән караңгы төшәчәк, Юрка килеп җитсә иде, ичмасам!

Бу утраудан өметен өзгәч, Валька икенчесенә йөгерде, куе камышларны аралап, сөзәк ярдан өскә күтәрелде. Нәкъ шул вакыт, яшен аткандай бөтен тирә-якны яңгыратып, мылтык шартлады. Тагын! Тагын!..

Валька, тәмам хәлсезләнеп, сыгылып төште. Мылтык тавышлары көмеш утрау ягыннан ишетелә иде... Яралы зәгыйфь кошка шулай кат-кат аталармы?..

Йөзтүбән капланып яткан малай әкрен генә чалкан әйләнеп, күккә бакты. Күктә биектә ике кош — ике үрдәк әйләнеп оча иде. Әллә юкса болар теге үрдәкнең кан кардәшләреме? Мылтык тавышларына да игътибар итмичә, шул рәвешле үзлә-

ренең яралы туганнарын эзләп очалармы? Барыгыз, кошкайлар, очыгыз җылы якларга. Инде... соңрак...

Валька яткан урыныннан күтәрелде, маңгаеннан саркып аккан канны кул аркасы белән сөртеп алды. Ул хәзер бәрелгән терсәге сызлауга да, сыдырылган маңгае әрнүгә дә битараф. Чөнки барысыннан да битәр күңеле әрни иде аның.

Малай, күңелендә шыксыз бушлык тоеп, сүлпән генә авыл ягына атлады.

Ярга чыгып, юлсыз-сукмаксыз җирдән өйләренә таба меңгәндә ул кинәт... каккан казык кебек катып калды, бер мәлгә күзләренә ышанмый торды. Аның нәкъ аягы астында, шырагай гына куаклар төбендә, тәмамысы җиргә сеңеп, аның үрдәге — көмеш утрау кошы ята иде.

— Үтти!... — дип пышылдады Валька. — Үтти-и-и, синме бу?..

Ул әкрен генә җиргә чүкте, саклык белән генә кулын сузды. Хәйран тамаша! Үрдәк йөгермәде, качмады, киресенчә, малайга таба талпынып куйгандай булды. Тик шәмәхә-зәңгәр муены соры каурыйлары арасына батып керде.

Валька сак кына үрелеп, кошны кулына алды, бишмәт изүен ычкындырып, куенына сыендырды. Шунда аның бөтен тәне буйлап биниһая рәхәт җылы дулкын йөгереп узды, ниндидер кайнар төен эчтән, йөрәк түреннән күтәрелеп, бугазын пешерде.

— Валька! Ва-алька-а! Син кайда-а?..

Бу — Юрка, шулай кычкыра-кычкыра, югалган дустын эзли иде:

— Син кайда, Ва-алька-а?..

Нечкә генә, чәрелдек кенә бу тавыш Ленаныкы. Көзге җил өзми-куймый авыл ихаталары ягыннан шул авазларны китерә. Ләкин Валька җавап бирергә кыймый, үрдәген, кадерле кошын куркытырмын, төзәлмәслек хата эшләрмен дип шикләнә. Әйтерсең аның куенында хәзер яралы зәгыйфь үрдәк түгел, ә бәлки асыл тавис кошы, бәхет кошы сыенып утыра иде...

ҖЕН МАЛАЕ

Беренче көнне үк бистә кешеләренең күзенә чүп булып керде ул малай. Алты-җиде яшьләр чамасында, көнҗәләдәй чәчләре һәрчак тузгып, як-якка тырпаеп тора, авызында алгы тешләре юк, шул сәбәпледерме, сүзләрен санап-санап кына дигәндәй, бик саран сөйләшә, кешегә каш астыннан сөзеп карый.

Ул килеп, ишегалдында күренү белән үк хәбәр таралды: әбисенә кунакка килгән, имеш. Ходай түземлек бирсен бу башкисәрнең әбисенә! Кем икәне күз карашыннан ук күренеп тора...

Һәм бик тиз арада юраганнар юш килде. Килеп әлгәшүенә ярты көн дә узмастан, бу чытлык бөтен ишегалдына хуҗа булып алды. Әйтерсең туа-тумыштан шушында яшәгән! Әбәткә кадәр ул барлык подъездларны айкап чыкты, төштән соң өч катлы йортның чарлагын пыран-заран актарып төште, подвалга кереп казынды. Шул рәвешле өйнең һәр почмагын иснәп-барлап чыкканнан соң, сарай түбәләренә, коймаларга, агач башларына үрмәләде. Анда да озак тоткарланмыйча, сикереп төшеп, сәрби куаклары астына чумды.

Ике кулына да базар букчасы күтәреп кибет ягыннан өлкән

яшьләрдәге бер юантык апай кайтып килә иде. Шунда кинәт өй артыннан әлеге тиктормас малай атылып чыкты. Йөгергән уңайга ул аш тәлинкәсе зурлыгындагы күгәргән калай банканы типкәләп тәгәрәтә иде. Асфальт тротуарда котсыз яман тавышлар чыгарып тәгәрәгән калай банка тавышына әлеге апай, кинәт сискәнеп, башын күтәрде:

— Фу-у, котымны алдың! Башка уен тапмадыңмы, күгәргән тимер тәгәрәтеп йөрмәсәң?

Әмма бу сүзләргә малайның сыңар керфеге дә селкенмәде. Әллә дәштеләр аңа, әллә юк. Әйтерсең бөтенләй ишетмәде дә, күрмәде дә. Күк күкрәгәндәй бөтен ишегалдын дер селкетеп, чатыр чаба бирде: шаңгыр-шоңгыр, шаңгыр-шоңгыр...

Бу сәер авазларны ишетеп, төрле подъездлардан урамга малай-шалай сибелде. Башта кайберләре бер мәлгә аптырап тордылар. Әйе, каян килгән әле безнең ишегалдына мондый көнҗәлә?.. Ә кайберләре шунда ук кызыклы уен белән мавыгып киттеләр. Почык борынлы, ак керфекле бер малай тегенең юлына аркылы төште:

— Каян алдың? Бир әле, мин дә тәкмәрләтим.

Чытлык малай, бер генә минутка тукталып, тегеңә кырын күз салды:

— Үземә кирәк.

Һәм янәдән шаңгыр-шоңгыр, шаңгыр-шоңгыр...

Эсседән әлсерәп, сәрби куаклары күләгәсендә йоклап яткан алабайлар, кинәт сискәнеп, һау-һаулап өрергә керештеләр, мәчеләр, куркынып, агач башларына сикерде. Өлкәннәрдән кемдер берәү шар ачык тәрәзәдән башын тыгып кычкырды:

— Туктат шалтыр-дөбереңне, башсыз балан куагы! Болай да эсседән баш мие кайный!

Шундый кызыклы шөгыленнән аерганга малайның кәефе кырылды, күрәсең. Ул авызын кыйшайтты, кашларын җыерды. Аннары, бер дә исе китмәгәндәй, чырт итеп читкә төкерде дә, тәкәббер генә атлап, банкасын чүәк башы белән этәрә-этәрә, үз подъездларына юнәлде. Ләкин ике-өч минутлар вакыт уздымы, юкмы, ул инде урам-тыкрыкларны бер итеп, янәдән чатыр чаба иде. Әлеге затлы-кыйммәтле уенчыгыннан аерылырга һичбер исәбе юк иде бу чытлыкның. Урамдагы башка малайлар һәммәсе каядыр китеп юкка чыктылар. Өлкәннәр күзенә чалынасылары килмәгән, күрәсең. Бу тикле доңгырдыктан хет колакларыңны томала! Моның өчен рәхмәт әйтүләрен көтәсе юк!

Бераздан күрше йорттан бик кыбырсык киенгән, баш түбәсенә кызыл бантик бәйләгән сары чәчле кызый йөгереп чыкты.

— Доңгырдатма! — диде ул, кырыс кына итеп.— Синең аркада безгә дә эләгер, юкса. Аңладыңмы? Чүплек башыннан күгәргән калай табып алган да...

Малайның ваемсыз йөзе кинәт үзгәрде. Җавап итеп ул һичбер сүз әйтмәде, ләкин аның гаять күп мәгънәле күз карашы әлеге кызыл бантикка текәлгән иде. Әгәр шул вакытта якында гына шыгырдап ишек ачылмаса, ай-һай, бу бантикның исән калуы бик тә шикле иде.

Кызчык, йөгерә-сикерә, өй почмагы артына кереп югалды. Ниндидер ашыгыч йомыш белән китеп барышы иде, күрәсең. Киткән икән, димәк, кайтасы да бар әле!..

Кояш рәхимсез кыздыра, асфальт тротуардан кайнар сумала исе бөркелә, әмма малай подъезд төбен уяу сагалый иде.

Әнә ул бәйләнчек кызый кайтып та килә. Ни-нәрсә өчендер бик шат күренә, һаман шулай йөгерә-сикерә атлый, ике кулында ике туңдырма. Баш очындагы бантигы кызыл күбәләк кебек җилпенә.

Малай астыртын гына як-ягына күз йөртеп чыкты: берәү дә күренми. Бәс, шулай булгач...

Ул, куак артыннан чыгып, кызыйның юлына аркылы басты:

— Ни кирәк сиңа?

— Нидерби.

— Бәйләнмәкче буласыңмы?

— Булам!

— Карап кара!

Алар, ике этәч кебек, бер-беренә каршы басып, шактый вакыт хәрәкәтсез тордылар. Кызыйның кулындагы туңдырмалары эреп, кызган асфальт өстенә тама башлады. Ул, ничек тә ычкынып качарга теләп, әле уңга, әле сулга тайпылды, әмма теге тигәнәк чат ябышкан: кызның һәр хәрәкәтен алдан ук абайлап, һәр омтылышына аркылы төшә, подъезд ишегенә таба бер генә адым ясарга да ирек бирми. Тегеләй дә, болай да янап карады. «Абыйга морожный алып кайтып киләм, эреп бетсә, арт сабагыңны укытыр»,— дип тә өркетмәк булды. Әмма әйттең ни, әйтмәдең ни бу сырганакка! Ярый әле, шунда башына тәвәккәл бер фикер килде.

— Ә-әй, түтәкәй, кара әле моны! — дип кычкырды ул, кинәт уң тарафка карап.

Әлбәттә, малай да ялт итеп шул якка карады. Кызыйга исә шул бер мизгел җитеп ашкан иде. Ул, җитез мәче кебек, җәһәт кенә сулга тайпылып, подъезд ишегенә чумды.

— Ярар, эләгерсең әле! — дип, зәһәрләнеп йодрык янады әлеге сырганак.

— Кырдың, ди, пычагымны! Кырдың, ди!..

Кызый, нәүмиз калган малайны үчекли-үчекли, югары катка менеп китте.

Шуннан соң бу тынгысыз малай күпмедер вакыт ишегалдында күренми торды. Ашарга кергән идеме, әллә берәр яры китеп барган идеме, әмма урам беразга тынып калды.

Тик бераздан барыбер үзенекен итте, явыз. Кызның суга чыккан чагын сагалап торды да, берни булмагандай тып-тыныч кына килеп, чиләгенә бер кепка ком сипте. Бу кадәрлесен кызый көтмәгән иде. Ул сулкылдап елап җибәрде. Үзенең мәкерле эшен җиренә җиткереп башкарган көнҗәлә баш, бик канәгать кыяфәт белән, шунда ук юкка чыкты.

Бу хәлләрдән хәбәрдар булган күрше-күләннең тәмам ачуы кабарды. Һәркем үз фикерен әйтүне кирәк тапты:

— Нинди тәрбиясез бала!

— Менә шушындыйлардан үсә инде ул урам сукбайлары!

— Нинди ата-ана үстерәдер мондый бәдбәхетне!..

Әлбәттә, хәзер инде аның белән беркем дә дуслашырга, аралашырга теләмәде. Бистә читендәге күлгә кармак салырга барсалар да, туп сугарга җыелсалар да, бистә малайлары һәрчак бу тиктормасны читкә тибәрәләр иде. Бәладән башаяк!

Икенче көнне һич көтмәгәндә һава бозылды, кинәт кенә төньяк тарафтан көчле җил исә башлады. Ул төркем-төркем ямьсез соры болытлар көтүен куып китерде, түбә калайларын дөбердәтте, ишегалдында үскән яшь каеннарны пыран-заран китерде.

Көннең көн буе өйдә утырып тәмам ялыккан бала-чага үзенә бер-бер шөгыль таба алмый гаҗиз иде.

Шул арада, тәрәзә ярыгыннан җил өргән кебек, өйдән өйгә бер сәер хәбәр таралды. Кибет янында бер сыерчык баласы оча алмый җәфалана, имеш. Күзен тасма белән бәйләп җибәргәннәр, имеш.

Моны ишетүгә һәркемнең күңеленә бер үк уй килде: «Шул әлеге чытлык малай эше түгелме икән бу? Аннан барысын да көтәргә була...»

Малай-шалай, капчык авызыннан сибелгән борчаклар кебек, урамга сибелде... Кайда икән ул бичара кошчык? Ничек ярдәм итәсе икән үзенә?..

Артык тиз йөгерүдән сулышлары капкан ике кызчык, кинәт шып тукталып, зәһәр җилдә иелә-сыгыла җилфердәгән яшь каенга күрсәтеп, кычкыра башладылар:

— Сыерчык, сыерчык! Әнә ул, әнә, килегез тизрәк!

Тиз арада малайлар да килеп җитте. Алар каен тирәсендә этешә-төртешә бәхәсләшергә керештеләр:

— Баскыч алып килергә кирәк,— дип тәкъдим итә арадан берсе.

— Әйдәгез, җыйнаулашып каен кәүсәсен селкетик,— ди икенчесе...

Бу бәхәс, ихтимал, кирәгеннән артык сузылган булыр иде. Ләкин шулчак, терсәкләре белән төркемне аера-аера, каен төбендә пәйда булган түгәрәк мәйданчыкка әлеге дә баягы көнҗәлә баш килеп керде. Һәм, килә-килешкә, аягындагы ботинкаларын ашык-пошык яшел чирәм өстенә салып ташлады да, куллары, аяклары белән каен кәүсәсен кочаклап, мәче җитезлеге белән өскә үрмәләде. Әле бил ныгытырга да өлгермәгән каен кәүсәсе уңга-сулга чайкалды, кичкырын тәмам котырынган салкын җил, аны тамыры белән кубарып ыргытырга теләгәндәй, һаман ыжгырды, сызгырды, неп-нечкә яшь ботакларны урап-урап, селтәп-селтәп, теше-тырнагы белән өскә үрләгән үҗәт малайны камчылады. Ап-ак зифа кәүсәнең хәтта түзә алмый иңрәп куйганы, әрнеп ыңгырашканы да ишетелә кебек иде. Хәзер... Менә хәзер ул биленнән сынып чыгар да, гөрселдәп-уфылдап җиргә авар, үз авырлыгы белән үзсүзле тешләк бу малайны да басыпсытып харап итәр кебек тоела иде.

Әмма шулвакыт сулыш алырга да куркып, әлеге тамашаның ахырын көткән төркем беравыздан «ах» итеп куйды. Чөнки җанфәрманга каен ботагына чат ябышып утырган сыерчык баласы, кинәт кенә ычкынып, җил очырган коры яфрак кебек, һавага күтәрелде һәм давыл ихтыярына бирелеп, якындагы ихаталарга таба очты. Шушы минутта бу бичара тере төерчек таш стенага бәрелеп, тәмам изелер, юкка чыгар кебек иде. Әмма шул хәвефхәтәрне ничектер тоемлап, сыерчык баласы иң-иң соңгы көченә канатларын җәһәт-җәһәт җилпеде...

Тиңе булмаган табигать зилзиләсе һәм шушы зәгыйфь кошчык тик бер минут, тик бер мизгел шулай йөзгә-йөз килеп

көрәштеләр. Һәм... тере төерчек җиңеп чыкты. Ул менә-менә җимерелеп төшәргә торган иске сарай түбәсенә барып утырды.

Малай, ике дә уйламастан, агач ботагыннан сикереп төште, шулвакыт шактый нык кайшалдырган сул аягына аксыйтуксый, сарай ягына йөгерде. Ул инде хәзер сарай кыегына терәлеп үк торган биек койма башына үрмәләде... Кырыкмаса-кырык җиреннән күгәреп ертылган түбә калае кулларны җәрәхәтләде, күзләргә күгәрек тузаны тулды. Шәрә бәпкә буенча югары үрмәләгән чакта аны чак-чак кына җил алып бәрми калды, ләкин аның үзе турында кайгыртырга бер генә минут та вакыты юк иде. Тик кошчык кына тагын очып китә күрмәсен. Әзгә генә, бик әзгә генә түзсен, бирешмәсен!

Ниһаять, ул, үрелеп, сыерчыкны кулына алды, уч төбендә йоп-йомшак каурый-мамыкка төрелгән чикләвек шәйле генә шушы... тормыш кисәкчәсенең леперд әвек җылысын тоеп, бер генә мизгелгә үзе дә никтер калтыранып куйгандай булды. Аннары, ниндидер рәхимсез шакшы куллар белән сыерчык күзенә бәйләнгән җептәй нечкә кара тасманы чишеп, җилгә очырды, кошчыкны күлмәк изүе аша куенына тыкты һәм үз гомерендә булмаганча сак һәм салмак хәрәкәтләр белән, сарай кыегыннан түбәнгә шуышты. Бу минутта аның йөзендә гомер булмаган самими рәхәт елмаю балкый иде.

ЭЧТӘЛЕК

КОМДАГЫ ЭЗЛӘР
3

АЛТЫНКАЙ
21

КӨМЕШ УТРАУ КОШЫ
28

ҖЕН МАЛАЕ
40

Киндер Иван

К38 Алтынкай. /Русчадан Габделхәй Сабитов тәрҗемәсе.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.—46 бит.

ISBN 5—298—00389—3

К $\frac{4803010201}{М132\ (03)-93}$ — 108—93

Издание для детей и юношества

Киндер Иван Федорович

Рассказы

(на татарском языке)

ИБ № 6410

Редакторы *Ф. Зыятдинова*

Художество редакторы *А. Тимергалина*

Техник редакторы *Н. Зәйнуллина*

Корректоры *С. Мифтахова*

Җыярга тапшырылды 30.12.92. Басарга кул куелды 2.09.93. Форматы 60×90¹/₁₆. Типогр. кәгазе № 2. «Литературная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 3,0. Шартлы буяу-оттиск 3,88. Нәшер-хисап табагы 2,59. Тиражы 50 000 экз. Заказ Ч-353. Бәясе ирекле.

Татарстан китап нәшрияты.
420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан республикасы Информация һәм матбугат министрлыгының
К. Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе типографиясе.
420111. Казан, Бауман ур., 19.